КАҺАРМАНЛЫК

Махсус хәрби операциягә иң күп егетләр киткән авылларны барладык

> 5

ИРКӘ БУЫН

Муллыкта, рәхәттә үскән балалардан ни көтәргә?

> 15

ЗӨФӘР ХӘЙРЕТДИНОВ:

«Аңлап җырлаучылар бик сирәк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 24 (29184) | Җомга | 23 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

kremlin.ru

ФАЙДАЛЫ УЕННАР

КАЗАН ИЛ ҺӘМ ДӨНЬЯ КҮЛӘМЕНДӘГЕ ВАКЫЙГАЛАРНЫҢ ҮЗӘГЕНӘ ӘВЕРЕЛДЕ

Татарстан башкаласында «Киләчәк уеннары» башланды. Тарихта тәүге мәртәбә уздырылган әлеге чараның ачылу тантанасына Россия Президенты Владимир Путин белән бергә Беларусь, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан башлыклары, башка илләрдән зур кунаклар килде. Дәүләт башлыгы Казанда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановтан республикадагы хәлләрне белеште, яңа хәрби очкычка Минтимер Шәймиев исемен биреп, аннары үзе күккә күтәрелде. Владимир Путин катнашында яңа медицина объектлары ачтылар һәм «Сибур»ның фәнни үзәген төзи башладылар. Россия Президенты рульгә үзе утырып былтыр ачылган М12 «Көнчыгыш» юлын да күреп кайтты.

> 2–3

ИЛ СЕЗНЕҢ БЕЛӘН ГОРУРЛАНА

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Ватанны саклаучылар көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар, кадерле ветераннар!

Бүген безнең илебез иң әһәмиятле дәүләт бәйрәмнәренең берсе – Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтә.

Бу тантанада Россиянең ватанпәрвәрлеккә һәм халкыбызның бердәмлегенә нигезләнгән данлыклы һәм бөек көрәшләре, җиңүләре тарихы ачык чагылыш таба.

Бөек Ватан сугышында, олы сынаулар узып, Ватаныбызның азатлыгын һәм бәйсезлеген саклап калган кадерле ветераннарыбызны бу бәйрәм уңаеннан аеруча җылы хисләр белән тәбриклим. Сезнең батырлыгыгыз, илебезгә булган чиксез мәхәббәтегез һәм тугрылыгыгыз турында якты хәтер безнең өчен һәрчак иң югары әхлакый маяк булып тора. Без бу изге хатирәләрне мәңге күңелләребездә сакларбыз һәм буыннан-буынга тапшыра килербез.

Локаль сугышларны һәм низагларны җайга салу, тынычлык миссияләрен үтәү барышында үз бурычларын лаеклы башкарган барлык ватандашларыбызга олы рәхмәтемне белдерәм.

Россия Федерациясе Кораллы көчләренең Югары башкомандующие Владимир Владимирович Путин җитәкчелегендә сугышчыларыбыз үзләренең хәрби бурычын бүгенге көндә махсус хәрби операция уздыру зонасында, Ватанга ихлас хезмәт итү үрнәге күрсәтеп, батырларча үти. Сезгә зур хөрмәт һәм рәхмәт хисләремне җиткерәм. Илебез сезнең белән горурлана. Ватанны саклаучыларны, аларның гаиләләрен, мөхтәрәм ветераннарыбызны, шулай ук барлык татарстанлыларны бәйрәм белән котлыйм. Сезгә нык сәламәтлек, рухи ныклык, иминлек, бәхет һәм уңышлар телим.

Ватанны саклаучылар көне белән Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, Россия Президенты вазыйфасына кандидат Владимир Путинның ышанычлы заты Минтимер ШӘЙМИЕВ тә котлады.

«Ватанны саклаучылар көне безнең илебез өчен аерым әһәмияткә ия. Россия Федерациясе – дөньяда иң зур һәм иң бай ил, шуңа күрә ул һәрвакыт үз суверенитетын сакларга бурычлы. Безнең көчсез булырга хакыбыз юк. Менә бүген дә, дус булмаган илләр Россияне юкка чыгарырга омтылганда, бөтен халык илебез Президенты тирәсенә ныклап тупланды. Владимир Владимирович әйткән иде: «Үз мәнфәгатьләребезне, кешеләребезне, мәдәниятебезне, телебезне, үзебезнең чикләрне саклаганда, бөтен халык Ватанны саклаучы булып тора». Аның белән тулысынча килешәм: һәрберебез үз урынында, барыбыз өчен дә кадерле рухи кыйммәтләрне һәм бердәмлегебезне саклый, үстерә һәм ныгыта ала. Һәм шулай тиеш тә.

Ватаныбызның азатлыгын һәм иминлеген, тынычлыгын һәм бөтенлеген яклаучы көчле һәм кыю кешеләрне Ватанны саклаучылар көне белән ихлас күңелдән тәбрик итәм. Ватан каршындагы изге бурычларын үтәгәндә һәлак булганнарга мәңгелек дан! Хәзерге вакытта илебез чикләрен саклап яуга керүчеләргә көч-куәт һәм сәламәтлек телим», – диелә котлауда.

«БАР ДА БИК ЯХШЫ!»

ВЛАДИМИР ПУТИННЫҢ ТАТАРСТАНГА СӘФӘРЕ НӘРСӘ БЕЛӘН ИСТӘ КАЛАЧАК?

Россия Президенты Владимир Путинның Татарстанга ике көнлек эш сәфәре вакыйгаларга шактый бай булды. «Киләчәк уеннары» ачылышыннан кала, бу сәфәр ниләр белән истә калачак?

kremlin.ru

Шәймиев очкычы

Казанга килгәч, иң беренче эш итеп Владимир Путинга Горбунов исемендәге Казан авиация заводында ракета йөртүче стратегик Ту-160М очкычларын күрсәттеләр. Аны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм башка рәсми затлар озатып йөрде. Президент яңа «аккош»ларның берсенә күтәрелеп, штурвал артына утырып та карады. Заводта йөргәндә, ул Ту-160М хәрби очкычына Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев исемен бирергә тәкъдим итте.

– Без Татарстанда бит. Әйдәгез, яңа очкычка Минтимер Шәймиев исемен бирәбез, – дип Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать итте Владимир Путин. «Рәхмәт, Владимир Владимирович. Ул моңа лаек», – диде республика Рәисе.

Сүз уңаеннан, Татарстанга эш сәфәренең икенче көнендә Владимир Путин хәрби очкычларның берсенә утырып, күккә дә күтәрелде. Югарыдан ниләр күренүе билгесез. Маршруты – хәрби сер. Президентның ярты сәгатькә якын очканы гына билгеле. Җиргә төшкәч, Владимир Путин хис-кичерешләре белән уртаклашты. «Шәп техника. Очкыч командирына әйттем инде, Оборона министрлыгы җитәкчелегенә дә кабатлыйм: хәрби көчләр составына кертергә мөмкин», – диде ул.

Очраштырган уеннар

«Киләчәк уеннары» башлану уңаеннан, Казанның һава капкасы күпсанлы дәрәҗәле кунакларны кабул итте. Ачылыш тантанасына кадәр Владимир Путин рәсми очрашулар үткәрде. Таҗикстан Президенты Эмомали Рахмон белән очрашу барышында Владимир Путин ике ил арасындагы хезмәттәшлекнең яхшы үсештә булуын искәртте. «Без бергәләп чишә алмаган бер генә проблема турында да белмим», – диде ул. Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёев белән очрашу барышында яклар «Киләчәк уеннары» турында фикер алышты. Казахстан Президенты Касыйм-Җомарт Токаев исә Владимир Путинга киләсе «Киләчәк уеннары»н Казахстанда үткәрергә тәкъдим итте. «Бик шәп», – дип җавап бирде Илбашы. Кыргызстан Президенты Садыр Җаппаров белән очрашу барышында да яклар хезмәттәшлек мәсьәләсен күтәрде. Билгеле булганча, Россия Кыргызстанның төп сәүдә-икътисадый хезмәттәше булып тора. Серб Республикасы (Босния һәм Герцеговина) Президенты Милорад Додик белән сөйләшкәндә, Владимир Путин ике арада электән үк урнашкан элемтәләрне тагын да ныгытуга ышаныч белдерде.

«Хатын-кызларны үгетләрбез»

Эш сәфәренең икенче көнендә Владимир Путин катнашында видеоэлемтә аша ике бина ачтылар һәм зур төзелеш башладылар. Татарстанда «СИБУР Холдинг» ширкәтенең Фәнни тикшеренүләр һәм технологияләрне киңәйтү үзәген төзи башладылар. Казанның 7 нче номерлы клиник хастаханәсендә исә Перинаталь үзәк ачылды. «Яңа комплекс – ил күләмендә дә иң зурларыннан берсе. Биредә елына 8 меңгә кадәр йөкле хатын-кызны кабул итәргә мөмкинлек бар», – дип сөйләде хастаханәнең баш табибы Артур Делян. Бу хакта сөйләшкәндә, Владимир Путин Татарстанда икенче һәм өченче булып туган сабыйлар саны артса да, 2019 елдан бирле туучылар саны тотрыклы кимүен искәртте. Моның мөмкин булган сәбәпләре арасында яшәү рәвешен һәм тормыш дәрәҗәсен дә атады ул. «Бәлки, пандемия дә тәэсир иткәндер», – дип тә өстәде Владимир Путин. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, чыннан да коронавирус «аяк чалган». Бу юнәлештә республикада эш алып барылуын да әйтте ул.

– Клиникалар бик яхшы. Ирләребез дә нык. Ә хатын-кызларны үгетләрбез, – диде Рөстәм Миңнеханов, уенын-чынын бергә кушып.

Казанда «Наташа» хосписы да ачылды.

Татарстанга сәфәре ахырында Владимир Путин быелтыр ачылган М12 «Көнчыгыш» юлын барып күрде. «КАМАЗ»га утырып, рульдә үзе килгән Россия Президенты автомобиль компанияләре җитәкчеләре һәм йөк машинасы йөртүчеләре белән очрашты.

Татарстан сынатмый

Владимир Путин Казанда гаҗәпкә дә калды. Бу хакта ул Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда әйтте.

Иң элек Илбашы Татарстан Рәисенә «Киләчәк уеннары»н үткәрергә булышканы өчен рәхмәт әйтте.

– Барысы да югары дәрәҗәдә оештырылган – Татарстанда һәрвакытта да шулай, сез моны эшли беләсез, – диде ул.

Владимир Путин әлеге уеннарның халыкара дәрәҗәдә үткәрелүен һәм ачылыш тантанасы республикада гына түгел, ил күләмендә дә лаеклы дәрәҗәдә узуын искәртте.

– Мондый зур чараны Татарстанда үткәрергә ышанып тапшырганыгыз өчен бик зур рәхмәт, Владимир Владимирович, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Кунакларыгыз өчен дә рәхмәт, алар бик канәгать.

Икътисадка бәйле саннарга күчкәнче, республика башлыгы махсус хәрби операция мәсьәләсенә дә тукталды, әлеге юнәлештә оештырылган эш турында сөйләде. «Хәрби бүлекчәләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә, һәлак булучыларның якыннарына ярдәм итүдә, иң мөһиме – без шефлыкка алган территорияләрдә эш дәвам итә», – диде Рөстәм Миңнеханов.

2023 ел йомгаклары буенча, Татарстанда тулай төбәк продукты 4 триллион 103 миллиард сум тәшкил иткән. Үсеш – 3,6 процент. Төп капиталга инвестицияләр күләме 1 триллион сумлык чикне узган. Республиканың салым мөмкинлекләре – 1,5 триллион сум, Татарстанның үз керемнәре – 481 миллиард сум.

– Татарстан барлык федераль программаларда да актив катнаша. Узган ел нәтиҗәләре буенча, Татарстанда уртача гомер озынлыгы 75 яшь тә 3 ай тәшкил итә. Торак буенча бик зур программабыз бар. Моңарчы беркайчан да бу кадәр күп төзегәнебез юк иде, әле кайчан гына 2 миллион квадрат метр торак төзү турында хыялландык, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Билгеле булганча, Татарстанда өченче ел рәттән 3 миллион квадрат метрдан да күбрәк торак кулланышка тапшырыла. Былтыр чираттагы рекордны куйдылар – республикада 3 миллион 436 мең квадрат метр торак төзелде. Бу хакта сөйләгәндә, «Ил буенча да бу кадәр күп төзегәнебез юк иде», – дип елмайды Владимир Путин.

Илбашы республикада җитештерелүче Ми-38 очкычларын да мактады.

– Ми-38 – яхшы машина, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, кайбер кыенлыкларны хәл иткәч, әлеге очкычка бәйле яңа мөмкинлекләр дә ачылган.

Татарстанда газлаштыру күрсәткече – 99,2 процент. Бүген республика территориясенең 99 проценты газлаштырылган.

– Без моны зур казанышыбыз дип саныйбыз, – диде Татарстан Рәисе.

Рөстәм Миңнеханов искәрткәнчә, программа алга таба да дәвам иттереләчәк. Чөнки республикада яңадан-яңа объектлар төзелә, аларны зәңгәр ягулыкка тоташтырырга кирәк.

Соңрак сөйләшүгә Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә кушылды. Владимир Путин һәм Минтимер Шәймиев кочаклаштылар һәм дусларча аралаштылар.

– Бар да әйбәтме? – дип кызыксынды Минтимер Шәймиев.

– Бар да бик яхшы, – дип җавап бирде Владимир Путин.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИРТӘГЕГӘ СӘЯХӘТ

СӘЯСИ ЛИДЕРЛАР УЕННАРГА ЯКТЫ КИЛӘЧӘК ТЕЛӘДЕ



tatarstan.ru

Спорт кына түгел бу!

Конфуций, Софья Ковалевская һәм Никола Тесла дәрес әзерләргә ярдәм итәчәк, шәһәрләр буенча аэротакси йөреячәк, Ай белән Җир шары арасын лифт тоташтырачак. Юк ла, ниндидер уйдырма фильм эчтәлеген сөйләвебез түгел. Якын киләчәккә якты фаразлар бу. Татарстан башкаласында узган «Киләчәк уеннары» халыкара турнирының ачылыш тантанасында тамашачылар киләчәк иленә сәяхәт кылды.

Дөнья спортына бүләк

Мәгълүм булганча, ачылыш тантанасына Россия Президенты Владимир Путин һәм дөньякүләм сәяси лидерлар, танылган спортчылар килде. Катнашучыларны дәүләт башлыгы сәламләде.

– Традицияләр һәм заманчалык, физик сәләтләр һәм акыл, спорт һәм технологияләр, фән һәм мәгърифәт бердәмлеге. Болар барысы да кешегә һәрьяклы үсеш өчен һәм тиз үзгәрүчән, ирекле, куркынычсыз дөньяда уңыш казану өчен бик кирәк. Спортның классик төрләрен һәм киберспортны берләштерү тәкъдиме нәкъ Россиядә туды, – диде Россия Президенты. – Безнең илебез дөньяның әйдәп баручы спорт державаларының берсе булып кала бирә. Без һәрвакыт спортны һәм аның югары гуманистик идеяләрен алга чыгару өчен чыгыш ясадык. «Киләчәк уеннары» – дөньякүләм спорт гаиләсенә бүләк ул.

Владимир Путин күп кенә халыкара чараларны кабул иткән һәм җиренә җиткереп оештыра белгән Казанга аерым рәхмәтен дә белдерде.

– Без зур спорт чараларын югары дәрәҗәдә оештырган Казан белән горурланабыз. Ярышларның күбесе нәкъ менә биредә, Казанда узды, – диде Россия Президенты. – Бу шәһәр, Татарстанның үзе кебек үк, «Киләчәк уеннары»ның эчтәлегенә, рухына бик туры килә. Үзенчәлекле, күпмиллэтле, төрле халыкларның мәдәниятенә бай, ата-бабаларның мирасын кадерләп саклый, шул ук вакытта һәрвакыт яңалыкка ачык, кыю рәвештә иң катлаулы проектларга алына ул.

Ярышларга хәер-фатиха биргәннән соң, сүзне башка сәяси лидерларга да бирделәр. Әйтик, Белоруссия Президенты Александр Лукашенко: «Алга, киләчәккә!» – дип, сүзен кыска тотты. Казахстан, Таҗикстан, Кыргызстан һәм Үзбәкстан Президентлары да үз телләрендә изге теләкләрен әйтте. Сүз уңаеннан, киләсе Уеннарны кайда уздыру турында дип баш ватасы да юк: Казахстан һәм Үзбәкстан лидерлары 2025 һәм 2026 елларда ярышларны үзләрендә кабул итәргә әзер булуларын белдерде.

Алда ни көтә?

Киләчәк турында бәян иткән ачылыш тантанасының төп мәгънәсе шул: бик тиздән санлы дөнья белән чынбарлык арасында чик югалачак (хәер, ул инде бүген дә юк диярлек). Замана мөмкинлекләре илләрне һәм шәһәрләрне уңайлырак, яхшырак, сыйфатлырак, матуррак итәргә булышкан, һәр өлкәгә яңалык алып килгән.

Әйтик, якын киләчәктә санлы китапханә барлыкка килмәгәе. Математика һәм физикадан өйгә эшне ничек эшләргә дип баш ватасы да булмас әле: укучыларга Никола Тесла, Софья Ковалевская үзләре үк ярдәмгә киләчәк!

Шәһәр эчендә зур тизлекле аэротаксилар, мизгел эчендә каланың бер башыннан икенче башына йөртүче транспорт та барлыкка килмәгәе. Шулай итеп, кеше кадерле вакытын «тимер ат»ларны көтеп утырыр өчен түгел, үзен камилләштерүгә сарыф итәчәк.

Микротузансуырткыч, баш миен тикшерүче махсус җайланмалар – болары медицина казанышлары. Дөнья океанын өйрәнү, су энергиясен мәгълүмат эшкәртү үзәкләре өчен файдалану – болары да киләчәк алгарышы.

Миллилек эзләгән җаныбызга да азык таптык. Ачылышта, аз булса да, татарлыкка да урын бирелгән иде. Әйтик, тантана башланыр алдыннан алып баручылар залга җыелган кунакларны Тукай телендә сәламләде, татарча сүзләр өйрәтеп карады. Катнашучы илләр парадын (107 ил!) исә тулысынча татар көйләренә («Каз канаты», «Ак калфагым төшердем кулдан» h.б.) тезмә бизәде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Бу кызык!

- «Киләчәк уеннары»н оештыруга 5,2 млрд сум акча тотылган.
- Ачылыш тантанасын Игорь Крутой командасы әзерләгән.
- Тантана 9 тематик өлешкә бүленгән иде.
- Дәүләт гимнын Эльмира Кәлимуллина һәм Дима Билан башкарды. «Киләчәк уеннары» гимнын исә Ваня Дмитриенко һәм ди-джей Smash тәкъдим итте.
- «Казан Экспо»да 3 мартка кадәр «Киләчәк шәһәре» эшли. Анда керү бушлай. Биредә киләчәккә якынайта торган кызыклы проектлар белән танышырга, чараларда катнашырга мөмкин.

Хезмәттәшлек

Дәвамы булачак

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казанга Россия Президенты Владимир Путин чакыруы буенча килгән зур кунаклар белән очрашты.

Казан Кремлендә узган очрашуда Беларусь Президенты Александр Лукашенко хөрмәтле кунаклар китабында язма калдырды, ә аннары алтын каләмен Рөстәм Миңнехановка бүләк итте. Күпне күргән сәясәтченең теләге мондый булды: «Иң яхшы карарларны имзалар өчен». Татарстан Рәисе узган елның апрелендә Беларусьта булганын искә төшереп, Александр Лукашенкога очрашуларның һәм эшлекле программаның уңышлы узганы өчен рәхмәтен җиткерде. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Беларусь – Татарстанның чит илләрдәге төп партнерларының берсе. Хезмәттәшлекне тагын да үстерү теләге бар. Татарстан Рәисе Беларусь Президентына республиканың Дуслык орденын тапшырды.

Рөстәм Миңнеханов Дуслык орденын Кыргызстан Президенты Садыр Җаппаровка да тапшырды. Сүз уңаеннан, 2022 елның маенда Татарстан Рәисе бу илнең Достук ордены белән бүләкләнгән иде. Казан Кремлендә узган очрашуда ике арадагы элемтәләрне тагын да ныгыту турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан бизнесны үстерү өчен инфраструктура булдыру тәҗрибәсе белән уртаклашырга әзер. «Без Кыргызстан икътисадының җитди үсеш алуын күрәбез. Машина төзелеше, фармацевтика, медицина, ИТ-юнәлешләрдә хезмәттәшлек итә алабыз», – диде республика башлыгы. 2023 елның 9 ае йомгаклары буенча Татарстан белән Кыргызстан арасында товар әйләнеше 99,5 миллион долларны тәшкил итте. Садыр Җаппаров Казанга 2011 елда Кыргызстан делегациясе составында килгәнен искә алды. «Безне төрки тамырлар, уртак традицияләр һәм кыйммәтләр, мәдәни һәм тел охшашлыгы бәйли. Шуның аркасында Кыргызстан белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләр динамик рәвештә үсә. Без үзебезнең нәтиҗәле аралашуыбызны югары бәялибез», – диде ул. Бу атнада Казанда Кыргызстанның Генераль консуллыгы ачылу ике арадагы хезмәттәшлекне тагын да үстерәчәк.

Казан Кремлендә Таҗикстан Президенты Эмомали Рахмон белән дә очрашу узды. Соңгы мәгълүматларга караганда, ике арадагы товар әйләнеше 30 миллион долларны тәшкил итә. Әлбәттә, бу күрсәткечне арттыру мөмкинлеге бар. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстанның нефть химиясе, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау, мәгълүматлаштыру кебек юнәлешләрдә хезмәттәшлек итү теләге бар. Таҗикстан да хезмәттәшлекне үстерү яклы. Эмомали Рахмон Россия һәм Таҗикстан хезмәттәшлеге буенча конференция кысасында Таҗикстан – Татарстан бизнес-форумын уздырырга тәкъдим итте. Ә хөрмәтле кунаклар китабында ул мондый сүзләр язып калдырды: «Татарстанда яшәүчеләрнең барысына да чын күңелдән игелек, иминлек һәм алга таба да чәчәк ату телим! Һәр йортта тынычлык һәм татулык булсын». Рөстәм Миңнеханов Эмомали Рахмонга да Дуслык орденын тапшырды.

Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә Зимбабвеның беренче вице-президенты Константино Гувейа Доминик Ньикадзино Чивенга, Кытай Халык Республикасы Халык сәяси консультатив советының Бөтенкытай комитеты рәисе урынбасары Чэнь У, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең мәгариф министры, спорт буенча баш идарәсе рәисе Әхмәд Бәлхул Әл Фәләси, Босния һәм Герцеговинадагы Серб Республикасы Президенты Милорад Додик белән очрашты.

Әйтеп кенә бактым

Зәхмәт

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бүген төнлә җүнләп йоклый алмадым. Бер уйлаганда, татлы йокымны качырырлык сәбәп тә юк кебек иде. Тик менә изрәп кенә китәм, кабарынкы, кызыл иреннәр, зур авызлар төшкә керә башлый да, шундук уянам. Минем яшьтәге кешегә ясалма иреннәр турында язу бик килешеп тә бетми инде. Укучыларым арасында: «Бу бабай ник теләсә кая тыкшына икән?» – дип уйлаучылар да табылыр. Ә мин күңелдәгене әйтмәсәм, тынычланмам кебек.

Әле XIX гасырның беренче яртысында ук иҗат иткән француз язучысы Виктор Гюго үзенең героинясы Эсмеральда турында: «Аның күзләре авызыннан зур», – дип сокланып язган. Димәк, уймак авызлар модада булган ул заманда. Әлбәттә, мода дигәннәре бер урында катып кала алмый инде ул. Язганнарым «мең-мең карт» зарларына да охшар, бәлки. Әмма мин табигыйлекне бетерүгә, табигый закончалыкларны санга сукмауга гомергә каршы булдым. Мәсәлән, хатын-кыз күкрәгенә элек яшәү чыганагы итеп караганнар. Ә тормышка «пастеризация», ягъни сөтне термик эшкәртү килеп кергәч, күп кенә хатын-кызлар бала имезүдән туктый һәм күкрәк күбрәк ир затын ымсындыруга хезмәт итә башлый.

Ә менә иреннәр…

Заманында нечкә ирен, кечкенә авыз макталган, алар, белгечләр әйтүенчә, гөнаһсызлык билгесе саналган. Ә хәзерге «үрдәк авыз» нәрсә була инде? Мода аналитиклары, психологлар сүзе белән әйтсәк, зур ирен – сексуаль ирек билгесе. Моңа ышаныргамы-юкмы, чистый аптыраш. Бит ирен калынайтучылар арасында өлкән яштәге ханымнар, җитмештән узган әбиләр, хәтта җитәкчелектә шактый югары урын биләүче сәясәтче хатын-кызлар да бар. Гүзәл затлар заман модасыннан читтә калмауны зур бәхеткә саный.

Бер яшь кенә кыз белән сөйләшеп тордым әле. Иреннәр зурайту шаукымын ул болайрак аңлатты. «Күз алдына китер, Риман абый, яшь кенә кыз гиалурон кислотасы керттерә дә, көзге каршына басып, кабарган иреннәренә соклана. Бу – модно, дип, бәхетле елмая. Һәм бәхетен тагын да арттыру өчен, тагын бер укол ясата. Һәр артык миллиметр аны бәхетле итә. Чик-чама онытыла, ирен кабарту төп максатка әйләнә», – диде. Мин аны ышанып-ышанмас кына тыңлаган идем. Интернетта актарына башлагач, күп кенә психологларның шул фикердә булуын, ирен калынайтуны, хәтта наркотик куллануга тиңләүләрен укып шаккаттым. Ә шаккатасылар алда булган икән әле. Израильнең бер табибы үзенең клиентларының 40 проценты ирләр икәнен язган. Монысы нәрсә инде тагын?

Без – «тәтәй чаба, мин дә чабам» дип яшәргә күнеккән халык. Яхшымы ул, яманмы, кайчак артын бик үк уйлап җиткермибез, модадан калмас өчен, «авызлыкны тешләп», алга чабабыз. Тик менә пластик операция ясаучы кайбер хирурглар әйтүенчә, мода үзгәрсә, ул калын иренлеләр нишләр? Израиль табиблары акча эшләүне төп максат итеп куйган белгечләрнең артуы, аларның шикле инъекцияләр куллануы турында да кисәтә.

Мин хәзер телевизор кабызырга да курка башладым. Шоу-бизнес әһелләре – бер нәрсә, тапшырулар алып баручыларның, тапшыруда катнашучы рәсми затларның заман зәхмәтен йоктырганнарын күреп, күңел кайта, кая барып җитәрбез икән, дип уйлап куясың.

Бүген – 21 февраль, тизрәк эшкә китим, «ВТ»да эшләүче кызларымны күрим. Аларның үз-үзен тотышлары да, йөз-кыяфәтләре дә табигый, күңел капкалары ачык. Кызларым янында булып, ясалма дөньядан бераз булса да арынып торыйм. Кабарынкы иреннәр турында аларга да сүз катканым бар, нәрсәдәндер җирәнгәндәй, борыннарын гына җыералар.

БИЛГЕ ӨЧЕН КӨРӘШ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Тверь өлкәсендә прокуратура мәктәп директорын 5 мең сумлык штрафка тарткан. Бу хакта өлкә прокуратурасы сайты хәбәр итә. Штраф директор вазыйфаларын башкаручы затның административ хокук бозуы өчен салынган. Сәбәбе мондый: бер малайның әнисе улының тарих дәресендә алган билгесен төзәтүне сорап мөрәҗәгать иткән, ә мәктәп җитәкчесе бер ай эчендә җавап бирмәгән.

Россия законы буенча, гражданин мөрәҗәгать иткәч, рәсми оешма бер ай эчендә җавап бирергә тиеш. Синең җавабың берниндә эчтәлексез формаль язу, ягъни отписка гына булырга мөмкин, әмма аның бирелүе мәҗбүри. Оешмалар гадәттә шулай эшли дә, бүре дә тук, сарыклар да исән, дигән мантыйк белән рәсми хат юллыйлар. Тверь өлкәсенең Фиров районында эшләүче мәктәп директоры бу хакта белмәгәнме, әллә белеп тә үзен ваемсыз тотканмы, мәгълүм түгел, ә штрафны барыбер түләргә туры киләчәк. Тарих укытучысы укучыны һәм аның әнисен канәгатьләндерә торган билге куймагач, эшләр менә шул рәвешле зурга киткән. Прокуратура мәгълүматына караганда, укытучыны да дисциплинар җавапка тартканнар, җәзаның нинди икәне әйтелми. Укытучының гаебе ничек ачыкланган, прокурорлар анысын да шәрехләп тормый.

Укытучының эше баланы һәм аның әти-әнисен канәгатьләндерә торган билге кую түгел. Аның бурычы – белемне объектив бәяләү. Әмма мәктәптә эшләү тәҗрибәм булганга шуны әйтә алам: бәя гадел булса да, күпчелек очракта канәгатьтәндерми. Укытучылар гадәттә билгене күтәреп куя, чөнки алардан тормаган хәлләр шуңа этәрә. Югары бәягә дәгъва белдерүче булмый. Андыйга кем каршы килсен инде?! Әле билгеләр югарырак булган саен, эшең дә югарырак бәяләнә. Мәктәп администрациясенең, балаларның һәм әти-әниләрнең күмәк психологик басымыннан качу өчен генә булса да, укытучы журналны югары билгеләр белән бизи.

Социаль челтәрләрдә таныш укытучыларның зарларын укыштыргалыйм. Хәзер бер дә белмәгән укучыга «дүртле» куйсаң да, гаепле буласың. «Бишле» таләп итәләр. Югарыда сөйләнгән очракта прокуратура укучының белемен ничек тикшергән, рәсми хәбәрдә бу хакта берни дә әйтелми. Бәйсез комиссия төзергә һәм укучыны шуның каршында утыртып, имтихан алырга кирәк була бит бу очракта. Андый адымга барсаң, укучы каушый һәм белгәнен дә онытa, димәк, тагын объектив картина барлыкка килми. Укучыга каныгып, түбән билге тезгән очраклар да булгалый, әлбәттә. Сирәк кенә. Бөтен Тверь өлкәсендә моннан соң укытучылар билге куйганда, аның үзләре өчен нәтиҗәсе ничек булачагын уйлаячак, анысына ышанам. Димәк, күрсәткечләр тагын да яхшырачак, белем дәрәҗәсе генә түбәнәячәк.

«Татар-информ»

Әти-әни баласын белем алырга өндәгәндә, максат итеп югары билгене сайлый икән, белем үзе булмый, күз буяулардан торган билгеләр пәйда була. Максатның дөрес сайланмавы гаиләнең үзенә дә, җәмгыятькә дә җимергеч тәэсир ясый. Бик сәләтле балалар, алдашырга өйрәнеп, ялкаулыкка күнегәләр, талантлар җиргә күмелә. Белем үзе таләп ителмәгәч, билге ясау белән генә шөгыльләнгән укытучы таланты да зәгыйфьләнә һәм юкка чыга.

Мәгарифтә исә дәреслек тә, методика да, укытучы таланты да түгел, мотивация төп рольне уйный. Дөрес мотивация табылса, аның белән таулар күчерергә була. Фикерне бер мисал белән сурәткә әйләндерик. Искә төшерик: кайчандыр Татарстан мәктәпләрендә татар теле мәҗбүри укытыла иде. Рус телле әти-әниләр, балаларның телне өйрәнә алмауларын сылтау итеп, зур тавыш кубарды, шаукымы Мәскәүгә барып җитте. Һәм нәрсә булса, шул булды: мәҗбүрилек бетерелде. Барыбыз да туган тел укытучыларын, дәреслек авторларын, методиканы сүктек. Ялгыштык дип әйтергә җыенмыйм, дөрес сүктек. Үзем хәзерге вакытта бер чит тел өйрәнәм. Бик күп укытучыларны һәм методикаларны карап чыктым, байтак сәгатьләр шөгыльләндем, нәтиҗәсе булмады. Бер мин генә түгел, башка бик күпләрнең тәҗрибәсе шуны күрсәтә: түләп, дәресләр алалар, сүзне сүзгә ялгый алмыйлар, лексика да юк, грамматика да. Ул укытучылар һәм методикалар белән телне өйрәнеп була булуын, бик көчле омтылыш кирәк. Бездә менә шул җитми. Тисә тиенгә, тимәсә ботакка дип атсаң, ботакка да тидерә алмыйсың. Үзем бер яхшы укытучыга тап булгач кына телнең рәтенә төшенә башладым. Беркөнне хатыным минем интернеттан дәрес алганны карап утыра. Укытучы русча җөмләне әйтүгә, мин аны чит телгә күчереп тә куям. «Син тәрҗемәче булып беткәнсең ич инде», – ди хатын, шаккатып. Әле һаман да белемем сай, лексикам ташка үлчәрлек икәнен үзем генә беләм. Шул дәрес кысасында гына беләм телне. Әмма нәрсә өйрәндем, шул онытылмый хәзер. Менә нәрсә эшләтә методика!

Хәзер инде Татарстан мәктәпләрендә татар теле укытуга кайтыйк. Кайсы гына мәктәптә, нинди генә укытучыдан белем алмасын, бер халыкның балалары татарчаны яхшы үзләштерә иде. Татар баласы үз туган телендә өч сүз дә әйтә алмый, теге халыкныкы сиптерә генә. Моны үз фантазиямнән чыгып әйтмим, ул елларда Мәгариф министрлыгындагы татар теле укытылышын тикшереп йөргән белгеч сүзләреннән чыгып әйтәм. Ике кеше: берсе – чиновник, икенчесе – тел галиме класска керәләр дә рәттән балаларны сөйләштерә башлыйлар икән. Тел буенча белемне тикшерүнең иң яхшы ысулы шул, язма эш тә кирәкми, журнал билгесе дә. «Яһүд баласы торып басса, бер кыенлыксыз сөйләшә, башка балалар авызына су кабалар», – дип әйтә иде министрлык белгече. Димәк, бу халыкның әти-әниләре балаларын: «Татар теле белән кая барасың?» – дип өйрәтмәгән, аны өйрәнүнең мөһимлеген аңлаткан һәм мотивация барысын да эшләгән.

Математика өйрәнәсеңме, физиканы, Менделеев дәвамчысы булырга телисеңме, омтылыш дигән бөек нәрсәдән башка таш урыныннан кузгалмый. Мәсьәләнең башка ягы да кискен булып калкып ята әле монда: мәктәптән укытучылар китә, чөнки хезмәт хакы дигән мотивация юк. Әле кичә генә ишеттем: 25 еллык стажын тутырган югары белемле укытучы «КамАЗ»га утырган. Татарстан буенча физика укытучылары вакансияләрен ачтым да хезмәт хакына күз салдым. Яшел Үзән районындагы гимназиягә физика укытучысы кирәк. Хезмәт хакы – 20–22 мең сум. Ничек уйлысыз: барачакмы белгечләр 5 февральдә эленгән бу вакансиягә эшкә?

ӨМЕТ

23 ФЕВРАЛЬ – ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

АВЫЛЛАР ЯУ КЫРЫНА КИТКӘН ИР-ЕГЕТЛӘРНЕҢ КАЙТУЫН КӨТӘ

Авыллар яу кырына үзенең ныклы терәге булган ирләрен, егетләрен озатты. Кайбер җирлекләр Ватан сагында торган кырыклап, утызлап солдатының туган якларына исән-имин әйләнеп кайтуын көтә. Мондый авылларда кешеләр бүген ничек яши? Каян көч алалар да солдат гаиләләренә ничек булышалар? Без егетләрен күпләп озаткан авылларның хәлен белештек.

Яшел Үзән

Бер җирлектән – 40 солдат

Яшел Үзән районының Норлат авыл җирлегендә 40 кеше хәрби операциягә киткән. Аларның 12се мобилизацияләнсә, калган 28е контракт буенча хезмәт итәргә карар кылган.

Билгеле, җирлек тә зур. Сигез авылда барлыгы 3057 кеше яши. Норлатның үзендә исә 2600 кеше гомер итә. Шуңа күрә Ватан сагында торучыларның да иң күбе шушы авылга туры килә. Кызганыч, һәлак булучылар да бар. Авыл җирлеге башлыгы Илдус Саттаров сүзләренчә, яу кырыннан ике егетләрен – Александр Смагин белән Ришат Муфазаловны кайтарып җирләгәннәр.

Аның әйтүенчә, авылда патриотик рух көчле. Контракт төзеп китүчеләр арасында исә 45 яшьтән өлкәнрәкләр дә бар. Аларның кайсыдыр хәрби тәҗрибәле, кемдер үзен чын патриот итеп хис итә, авыр хәлдә калып, тормыш шартларын яхшыртырга теләп яуга кузгалучылар да бар.

> Авылыбызның ныклы, төпле егетләре китте. Аларны эш урыннарында вакытлыча алыштырып торалар. Вакытлыча гына булганда түзәргә була ул, иң мөһиме – тиз арада тынычлык урнашсын да, егетләребез исән-сау әйләнеп кайтып, гаиләләренә дә, авылга да ныклы терәк булсыннар иде, дип телибез, – диде ул.

Уллары, ирләре хәрби операциядә булган хатын-кызлар ярдәм сорап еш мөрәҗәгать итмиләр икән. Күпчелеген утын хәстәрләү мәсьәләсе генә борчый. Андыйларга вакытында ярдәм итәргә тырышалар. Аның каравы авыл халкы яу кырындагы егетләрне ярдәмсез һәм игътибарсыз калдырмый. Авыруларны алып чыгарга носилкалар, маскировка челтәрләре, эчке киемнәр, мендәр, урын-җир кирәк-яраклары тегәләр.

– Бу борчу-мәшәкатьләр бар халыкны берләштерде. Уллары һәлак булган аналар да гуманитар ярдәм әзерләүдә актив катнаша. Алар шулай күңелләренә аз булса да тынычлык алуларын әйтәләр. Үзебезнең авыллар гына түгел, күршеләр дә кушылды. Гуманитар ярдәмне берләшеп, бергәләшеп җыялар. Безнең җирлектән генә дә егерменче тапкыр гуманитар ярдәм җибәрдек, – диде Илдус Саттаров. – Мәчетләргә йөрүчеләр, дингә тартылучылар да артты. Гел зарланып, елап кына да утырып булмый бит. Алга таба яшәргә, тормышны алып барырга, балаларны аякка бастырырга, яу кырында булганнарга матди генә түгел, рухи ярдәм дә күрсәтергә кирәк. Шуңа күрә ара-тирә бәйрәмнәр дә, төрле чаралар да үткәреп торабыз. Мәсәлән, шушы көннәрдә төрле спорт ярышлары буенча спартакиада башланып китте.

Мамадыш

Берләшү һәм көтү

Мамадыш районының Көек-Ерыкса авыл җирлегенә ун авыл керә. Алардан 27 кеше Ватан сагына баскан, шуларның 11е мобилизацияләнгән. Китүчеләр барлык авылдан да бар, тик халык саны күбрәк булган Яңа Комазан, Зур Шыя, Гришкино авылларыннан иң күбе. Араларында башка җирләрдә яшәп, авылда пропискада булучылар да бар.

Кызганыч, әлеге җирлек тә ике егетен югалткан.

– Аларның берсе хәрби операция башлангач ук Ульяновскидан контракт төзеп китте. Икенче егетебезне авылдан озаттык. Мобилизацияләнүчеләр яшьләр булса, килешү төзеп китүчеләр арасында 50 яшьлекләр дә бар. Бүген яуда булганнар белән һәрдаим элемтәдә торабыз. Аларның үзләренә дә, гаиләләренә дә ярдәм итәргә тырышабыз. Кемгәдер утын кайтартабыз, кемгәдер тегендә-монда барып кайтыр өчен машина биреп торабыз, вак-төяк эшләрдә булышабыз. Бәйрәмнәрдә дә әлеге гаиләләр – игътибар үзәгендә. Әле менә шушы көннәрдә ике гаилә өйләренә су кертүне сорап мөрәҗәгать итте. Быел аларга шушы эшләрне эшләп чыгарга ниятлибез, – диде җирлек башлыгы Фидаил Шәйхетдинов.

Исәннәрне генә түгел, һәлак булучыларны да онытмыйлар. Яшьли гомерләре өзелгән егетләр истәлегенә спорт ярышлары уздыру үзенә күрә бер традиция рухын алган икән инде.

– Бу вакыйгалар кайбер авыл халкын икегә бүлгән икән, дип ишетергә туры килә. Бездә андый күренеш юк. Күрше борчуы бар кеше борчуына әйләнде. Киресенчә, авыл берләште дип саныйм. Тарткалашу, үпкәләшүләр булганын белмим. Хатын-кызлар бар эшне бергә эшли, солдат әниләренә һәм хатыннарына ярдәм итәләр. Авылдашлар җыйган акчага газ плитәсе, бензин пычкысы алып җибәрдек. Апаларыбыз җыелышып, токмач та кисте, чәкчәк тә пешерде. Һәр солдатка атап посылкалар салдык. Ничек булдыра алабыз, шулай ярдәм итәргә тырышабыз. Ялга кайткан һәр солдат белән күрешәбез, хәлләрен белешәбез, мәктәпкә чакырып, укучылар белән очрашулар уздырабыз, – диде Фидаил Шәйхетдинов.

Ә менә үз авылларында эш булмагач, ир-атларның күпчелеге башка авылларга, районга, шәһәргә барып эшләгән булганнар. Шуңа күрә хезмәт урыннары буенча авырлыклар юк.

– Җирлектән шул кадәр егетебезнең ут эчендә булуы горурланыр өчен сәбәп була алмый, – дип саный Фидаил Шәйхетдинов. – Алар тегендә ут эчендә булса, без – монда. Гаиләләре генә түгел, без, авылдашлары да, һәркайсының исән-имин әйләнеп кайтуын телибез. Хәлләрен белешеп, матур яңалыклар гына көтәбез. Авыл җыеннарында да әниләрен, хатыннарын җыеп, бүләкләр биреп, кунак иттек. Аларның һәркайсы үзебезнеке, үз авылыбызныкы бит.

vk.com

Мөслим

«Ир-ат кулы җитми»

Мөслим районының Шуган авыл җирлегеннән 18 ир-ат хәрби операциягә киткән. Ир-егетләрнең 15е – 473 кешелек Рус Шуганы авылыннан. Алты кеше мобилизацияләнгән булса, калганнары – үз теләкләре белән китүчеләр. Аларның исә күпчелеге – 50 яшьтән өлкәнрәк ир-атлар. Әйтик, быел гына хәрби операция сафларын тулыландыручы ике кеше 60 һәм 62 яшьләрен тутырган. Андыйларны туган якларында буй җиткергән балалары һәм оныклары көтә.

– Бездә чын патриотлар бик күп. Берсен дә үгетләү дә, мәҗбүриләү дә кирәкми. Контракт төзеп китүчеләрнең һәркайсы белән сөйләшкәнем булды. Барысы да бертөрле фикер әйтә: «Тормыш тәҗрибәбез җитәрлек, барысын да диярлек беләбез. Безне озаклап өйрәтеп торырга кирәкми. Без җиңәргә тиеш». Кызганыч, мобилизацияләнгән бер егетебез һәлак булды. Иван Шильновның якты истәлегенә укыган мәктәбендә мемориаль такта ачылды. Яралнучылар да булды. Бер кешебез инде өченче тапкыр яраланып кайтты. Дәваланып, хәл алалар да кабат иптәшләре янына китәләр. Китүчеләрнең барысы да ялга кайтты, һәркайсы белән күрешеп, сөйләшеп калырга тырышам, – ди Альбина ханым.

Аның сүзләренчә, яуга киткән ир-егетләрнең 80 проценты – гомере буе авылда яшәүчеләр. Сала ныклы терәкләреннән башка яшәргә өйрәнеп килсә дә, аларның булмавы барыбер үзен сиздерә, ди ул. Әйтик, авылда фермалар да, сәнәгать оешмалары да булмаганлыктан, күпчелеге үз хуҗалыкларында күпләп терлек асрап көн иткән. Хәзер исә бу эшләр хатын-кызларга һәм балаларга калган. Тик ир-ат кулы булмагач, малларын киметүчеләр дә күп икән. Кемдер – 2–3 сыерын киметсә, кайсылары мал-туарын бөтенләй бетергән.

– Хатын-кыз ничек кенә көчле булырга тырышса да, хуҗалыкта ир-ат булмау барыбер үзен сиздерә инде. Безнең бурыч исә андыйларга булдыра алганча булышу. Мунчаларына утын сорап килүчеләргә утын алып кайтып бирдек. Бер егетебезнең әнисе шифаханәдә дәваланып, ял итеп кайтты. Контракт буенча хезмәт итүче егетебезнең милкен рәсмиләштерүдә ярдәм итәбез. Яу кырындагыларга гуманитар ярдәм әзерлибез. Дару, кирәк-ярак, ризык, окоп шәмнәре җибәрдек. Без монда сынатмабыз анысы. Иң мөһиме – киткәннәр кире әйләнеп кайтсын да озатучыларга якыннарын сау-сәламәт килеш каршы алырга язсын.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЫШАНМА СҮЗЕНӘ

Кисәтә торалар, алдана торабыз. Кызганыч, мошенникларга бәйле вазгыять әле һаман әнә шушы кыска гына формулага барып тоташа. Аларның бик оста психолог икәнен дә, яңадан-яңа алдау ысулларын уйлап чыгарып торуларын да бик яхшы беләбез югыйсә. Уяулыкның чиге кайда? Мошенник төп башына утырткан очракта ни эшләргә?



ru.freepik.com

Үзәк банк мәгълүматларына караганда, узган ел мошенниклар ил халкының 15,8 миллиард сум акчасын урлаган. Ел дәвамында кырыгалдарлар 1,17 миллион ялган операция башкарган. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, 33 процентка күбрәк, ди белгечләр. Узган ел Татарстанда дистанцион рәвештә кылынган мошенниклык аркасында халыкка 4,223 миллиард сумлык зыян салынган. Урланган акчаның нибары 261,8 миллион сумын гына кире кайтара алганнар. Телефон аша халыкны төп башына утырту буенча Татарстан Идел буе төбәкләре арасында әле дә булса беренче урында кала бирә. Ил күләмендә исә республика бу яктан бишенче урында.

Күптән түгел Татарстан Дәүләт Советының чираттагы утырышында да мошенниклар тарафыннан иң еш кулланылган алдау ысуллары турында сөйләштеләр. Татарстан буенча эчке эшләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Алексей Соколов республика хокук сакчыларының 645 тапкыр чит төбәкләргә командировкага барып, дистанцион рәвештә халыкны алдап яткан 321 кырыгалдарның эзенә төшүен искәртте.

– Узган ел мошенникларга ярдәм иткән арадашчы курьерларны да, алдагы ел белән чагыштырганда, ике тапкыр күбрәк тоткарладык. Шуларның 144е – безнең республикада яшәүче 16–23 яшьлек кешеләр. Алар мошенник корбаныннан акчаны барып алып, шуны алдан әйтелгән счетка күчерергә тиеш булган. Моны безгә дошман булган илдә яшәп ятучы җинаятьчеләр өйрәтеп ятуын да белеп эшләгән алар. Быелның гыйнвар аенда шундый кырын эшкә кереп киткән берничә студентны тоткарларга өлгердек инде. Дүртесе дә Аксубайның универсаль технологияләр техникумында укый. Алар Зәй, Чистай, Мамадыш һәм Азнакай районнарында яшәүче беркатлы әби-бабайларны алдап йөргән. Өч ай эчендә аларга барлыгы 3 миллион сумнан артык матди зыян салынган, – дип сөйләде Соколов.

Билгеле булганча, күптән түгел хокук сакчылары мошенникларның арадашчыларын да җинаять җаваплылыгына тарта башлады. Элегрәк курьер булып еш кына таксистлар йөргән булса, бүген җинаятьчеләр үзләренә ярдәмчене, нигездә, «Телеграм» каналы аша таба икән. Яшүсмерләр дә бу тозакка, нигездә, әнә шул рәвешле каба. Шуңа күрә, эш тәкъдим иткән белдерүләрдә нәрсәнедер илтеп биргән, алып кайткан өчен бик зур акча вәгъдә итсәләр, шикләнергә кирәк, ди белгечләр.

Мошенникларга каршы көрәш максатында кабул ителгән законнар да вазгыятьне үзгәртә алмый. Хәтерләсәгез, ике ел элек шундый канунларның берсе үз көченә керде. Аның нигезендә кәрәзле элемтә операторларына шикле тоелган, кырыгалдарлык очракларында кулланылган номерларны автомат рәвештә «тундыру» хокукы бирелде. Әмма вазгыять әллә ни үзгәрмәде. Хәзер белгечләр быелның июленнән гамәлгә керәчәк канунга зур өмет баглый. Аның нигезендә банк клиентларына югалткан акчаларын тулысынча кире кайтарырга тиеш булачак. Әмма бу акча банк гаебе белән юкка чыккан очракта гына кире кайтарылачак. Әгәр кешенең акчасы күчерелгән счет Үзәк банкның «кара исемлеге»ндә һәм банк анда акча күчүгә юл куйган икән, ул клиентына югалткан акчаларын кире кайтарырга тиеш булачак.

Узган ел кемнәр күбрәк алданган?

Хатын-кызлар	55,5%
Ир-атлар	44,5 %

(Үзәк банк мәгълүматлары буенча)

Фикер

Динара ХӘМӘТВӘЛЕЕВА, КФУдагы Психология һәм белем бирү институтының педагогик психология кафедрасы өлкән укытучысы:

– Белем һәм IQ дәрәҗәсе югары булган кеше дә мошенник корбанына әверелергә мөмкин. Монда кешенең шәхси сыйфатлары күбрәк роль уйный. Артык ярдәмчел кеше, гадәттә, мошенниклар тарафыннан ешрак алдана. Җиңел баюга кызыккан кеше дә бу капкынга тиз эләгә. Артык курку да зыянлы. Банкның куркынычсызлык хезмәте, полиция иише сүзләрне ишетүгә, кеше югалып калырга, куркудан үзе турында бөтен мәгълүматны әйтеп ташларга мөмкин. Шуңа күрә куркуны да җиңә белергә кирәк. Кешегә иярергә яратучылар да харап булырга мөмкин. «Менә монда күп кеше акча эшләде инде» дигән сүзне ишетүгә, килеп каба алар. Шуңа күрә телефон аша билгесез затлар белән гомумән сөйләшмәскә, сөйләшкән очракта да һәр нәрсәгә тәнкыйть белән карарга, анализларга кирәк. Телефонның икенче очындагы кеше сезне ашыктыра, басым ясый, артык тырышып үгетли, ике сүзнең берендә исемегезне әйтеп, ышанычыгызны яуларга тырыша икән – шикләнергә җирлек бар. Мошенникларның яратып кулланган ысуллары бу. Аларның эмоциональ интеллекты бик югары. Алар кешенең күңел халәтен шундук сизеп ала, алга таба шуннан чыгып бик оста эш итә.

Юрист Роман АРХИПОВ киңәшләре

1 Әгәр мошенниклар сезнең исемгә кредит рәсмиләштергән яки исәп-хисап счетындагы акчагызны урлаган икән, алданууыгызны күрсәтеп, полициягә гариза язарга кирәк.

2 Ялган юл белән сезнең исемгә кредит алынуын әйтеп, банкка да гариза язасы булачак. Гаризага полициягә язган гаризагызның күчермәсен дә беркетегез. Шулай ук банктан кредит счеты буенча өземтә бирүләрен сорап та гариза язарга кирәк.

3 Полициядә сезнең эшне кемгә тапшыруларын ачыклап, шул кеше белән көрешен сөйләшергә кирәк. Биредә сезнең мошенниклар тарафыннан алданууыгызны дәлилләгән документлар (исәп-хисап счетыннан өземтә, мошенниклар белән мессенджерларда язышканны исбатлаучы скриншот һ.б.) җыярга кушачаклар.

4 Гадәттә, кредит кырыгалдарлар тарафыннан рәсмиләштерелгән очракта, алар акчаны башка счет яки картага күчергән була. Ул кредит счеты буенча өземтәдә күренәчәк. Тикшерүче соравы буенча банк шушы карта яки счетның кем исеменә ачылганлыгы турында мәгълүмат бирергә тиеш. Бу очракта югалткан акчаны кире кайтару ихтималы бермә-бер арта.

НИЧЕК АЛДЫЙЛАР?

«Банкның куркынычсызлык хезмәте, полиция хезмәткәре борчый»

Һәр ике очракта да кырыгалдар кешенең исеменә кредит алырга яки аның счетындагы акчаны урларга маташулары турында сөйли. Узган ел Татарстанда теркәлгән мошенниклык очракларының 39 проценты нәкъ менә шундый юл белән кылынган. Шундый очракның соңгысы узган елның декабрендә теркәлгән. Мошенниклар Казанның Авиатөзелеш районында яшәүче бабайны, төп башына утыртып, 8 миллион сум акча сораган. Бабай аны түләү өчен 4 миллион сумга фатирын саткан.

«Кайда яшәгәнеңне беләм»

Схемасы гади: телефонга шалтыраткан билгесез зат үзенең тиздән иреккә чыгачагын һәм аның кайда яшәгәнен белүен әйтә, акча әзерләп куярга куша. Кеше бер шоктан айнырга да өлгерми, шундук башка номердан икенче берәү шалтыратып, үзенең полициядән булуын әйтә һәм: «Әле генә сезгә шикле номердан шалтыратканнар. Җинаятьченең эзенә төшәргә ярдәм итсәгез иде. Якындагы сәүдә үзәгенә килегез, үзегез белән акча да алырга онытмагыз. Җинаятьче сезнең кулдан акча алганда, аны шундук эләктереп алачакбыз», – дип башны әйләндерә.

«Милкегезне тартып алмакчылар»

Мондый ысул белән, нигездә, әби-бабайларны төп башына утырталар. Мошенниклар аларга шалтыратып, билгесез затларның аларның фатирын үз исеменә күчерергә маташуларын әйтә һәм, алар аны үз исеменә күчерергә өлгергәнче, фатирны тиз арада сатарга киңәш итә. Шул арада риелтор да килә, милекне сатып алучы да табыла. Шул рәвешле кеше фатирсыз да, акчасыз да кала. Узган ел бер Мәскәүдә генә әлеге юл белән алданган 20 пенсионер урамда калган.

«Картагызның срогы чыга»

Башта кешегә элемтә компаниясе исеменнән шалтыратып, сим-картасының яраклылык вакыты чыгуын хәбәр итәләр. Иртәгә телефоннан шалтыратып та, интернетка кереп тә булмаячак, шуңа күрә тиз арада яңасын чыгарырга кирәк, янәсе. Моны Дәүләт хезмәтләре порталы аша тиз арада эшләп була дип ышандыралар, кешенең паспорт, СНИЛС номерларын соратып алалар. Аннары аның порталдагы шәхси битен җимереп, аның исеменә кредит рәсмиләштереп куялар.

«Отышлы инвестиция ясагыз»

Мошенниклар биржа фондына акча кертеп, аннан көненә 100–200 процент күләмендә табыш алырга тәкъдим итә. Бу очракта да кырыгалдар, нигездә, телеграм-канал аша эш итә. Күптән түгел Түбән Камада яшәүче пенсионер биржа фондында шушы юл белән акча эшләргә теләп, 3 миллион сум акчасыннан колак каккан. Узган ел республикада мошенниклар тарафыннан алданучыларның 18 проценты нәкъ менә отышлы инвестиция ясарга теләп, ярык тагарак янында калган.

АДАШМА ЧЕЛТӘРДӘ!

ИНТЕРНЕТ ДӨНЬЯСЫН ГИЗГӘНДӘ НИЧЕК МОШЕННИКЛАР ТОЗАГЫНА ЭЛӘКМӘСКӘ?

Заманасы шундый: хәзер киберкуркынычсызлык, мәгълүматны саклау турында ешрак сөйләшәбез. Тормышыбызның күп вакыты интернетка бәйле булгач, нишләмәк кирәк? Хәзер иң зур байлык та – мәгълүмат. Аны ничек сакларга соң? Мошенниклар корбаны булмас өчен, нишләргә? Ничек итеп дөрес пароль куярга?

Бу һәм башка сорауларга «Касперский лабораториясе»нең Идел буе федераль округындагы клиентлар белән эшләү менеджеры Азат ШӘЙХЕТДИНОВ җавап бирде.

Мәгълүмати куркынычсызлык – ни ул?

Бүген инде мәгълүмати куркынычсызлык темасы ниндидер чит-ят темалардан саналмый. Бу – чын мәгънәсендә безнең чынбарлык. Ул компьютеры йә телефоны, интернетка тоташу мөмкинлеге булган һәркемгә кагыла.

Киң мәгънәдә караганда, мәгълүмати куркынычсызлык дигәндә мәгълүматны рөхсәтсез файдалану, үзгәртү яисә юк итүдән саклауны аңлыйбыз. Киберкуркынычсызлык мәсьәләсе хәзер бигрәк тә актуаль, чөнки кешеләр шактый вакытын интернетта уздыра, шәхси һәм шәхси булмаган мәгълүмат белән челтәрдә уртаклаша. Ә бит араларында аеруча кыйммәткә ия мәгълүматлар да бар.

Нинди киберһөҗүмнәр бар?

Нәрсә аеруча куркыныч тудыра соң? Болар – шәхси сәхифәләрне, аккаунтларны «җимерү» (взлом), мәгълүматны югалту, мошенниклык, зыянлы контент. Киберҗинаятьчеләрнең төп максатлары – мәгълүматны урлау яисә соратып алып урлау, акча урлау.

Нәрсәгә игътибар бирергә?

Гомумән, челтәрдәге теләсә нинди мәгълүматны сакларга кирәк. Әмма конфиденциаль, шәхси һәм яшерен дип саналганнары да бар. Бу, беренче чиратта, документларның фотолары, дәүләт хезмәтләрендәге шәхси мәгълүмат, банк карталарына бәйле мәгълүмат, төрле шәхси номерлар, шәхси фотосурәтләр. Шәхси мәгълүматны санлы дөньяга – төрле сайт һәм сервисларга кертүдә, аларның мошенниклар кулына эләкмәвенә ышаныч булу гаять мөһим.

Татарстанлылар күбрәк нинди кибертозакларга эләгә?

2023 елда Россиядә мобиль җайланмаларга карата башкарылган киберһөҗүмнәр саны кисәк кенә артты. Татарстанда гына да бу сан 635 меңне тәшкил итә. Бу һөҗүмнәр гаджетларга, нигездә, рәсми кушымта рәвешендә троян вирусы булып килеп керә. Мәсәлән, җинаятьчеләр, ялган банк кушымтасы ясап, акча урларга тырыша. Шулай ук кирәксез реклама да бик популяр. Әйтик, нинди дә булса кушымтаны ачкач калкып чыга ала. Шуны күрсәтеп, кырыгалдарлар акча эшләргә тырыша.

Тагын бер куркыныч тудыра торган нәрсә – шпион программалар. Алар кырыгалдарларга гаджетта булган барлык мәгълүматка үтеп керергә мөмкинлек бирә. Аеруча үсеш алган программалар хәтта кешенең җайланмасы белән идарә итә, күзәтү алып бара. Бу шпионнар үзләрен белдертмәскә, әмма шул ук вакытта шәхеснең бик күп мәгълүматын кулга төшерергә мөмкин.

Хәзер смартфон ияләре өчен тагын бер баш бәласе – рәсми булмаган, чит ресурслардан гаджетларга йөкләтелә торган кушымталар. Күп кенә Россия кушымталары чит илләрдә эшләми яисә чит илнекеләр безнең илдә эшләвен туктатты. Аларның альтернативаларын эзләү мәгълүмати һөҗүмнәр офыгын тагын да киңәйтеп җибәрмәгәе.

Социаль челтәрләрдәге куркынычсызлык

Еш кына зарарлы программалар безнең җайланмаларга төрле мессенджерлар аша эләгә. Әйтик, ниндидер популяр социаль челтәрнең альтернатив варианты рәвешендә. Мисал өчен, «Телеграм»да шундый алдау схемасы булуы ачыкланды: мошенниклар, валюта алмашу хезмәтен тәкъдим итәбез дип, кешеләрнең шәхси мәгълүматын да, акчасын да урлады.

Мошенниклар бик яратып куллана торган киберһөҗүм ысулы ул – фишинг. Бу – онлайн мошенниклыкның бер төре. Кырыгалдарлар бу очракта еш кына төрле рәсми, танылган сайтларның «игезәге»н уйлап таба. Кеше шул сайтларга юлыкса, ышанса, сайтта ниндидер эш башкарса, мошенниклар булган мәгълүматны үз кулына төшерә. Әйтик, парольләр, банк картасы мәгълүматлары. 2023 елда Татарстанда гына да «Касперский лабораториясе» 1 млн 427 меңнән артык фишинг «бит»ләргә кучү омтылышларын чикләде.

Тагын бер шикле ысул – скам-схема. Еш кына бу – «алдакчы» хәбәрләр, игъланнар, акчалата керем вәгъдә итә торган белдерүләр. Мәсәлән, лотереяда катнашырга чакыру яисә акча оту турында хәбәрләр. Басым ясыйлар, ашыктыралар икән, бу – димәк, алдакчылар.

ru.freepik.com

Мошенниклардан ничек сакланырга?

Җинаятьчеләр кулына логин һәм парольләр эләксә, алар аккаунт хуҗасы исеменнән эш итәчәк. Акчага бәйле кырын эшләр башкарырга да мөмкиннәр. Хәзер интернет кулланучыга кибергигиена күнекмәләрен үзләштерү, файдалы санлы гадәтләр булдырыр өчен менә дигән вакыт.

Пароль нинди булырга тиеш?

Шунысын истә тотарга кирәк: мәгълүматны саклауның мөһим өлеше булып пароль тора. Хәтта ки сез «двухфакторная аутентификация» дигән ысулны кулланган булсагыз да, парольнең әһәмияте кимеми. Шуңа да пароль уйлап табуга һәм аны саклауга җитди карарга кирәк.

Пароль киберһөҗүмнәргә каршы торырлык, 12 билгедән дә кимрәк булмаска тиеш. Шулай ук парольдә махсус символлар, саннар булырга тиеш. Баш хәреф һәм юл хәрефләр кулланырга кирәк.

Тагын бер мисал китерим әле. «Касперский лабораториясе» оештырган сораштыруга күз салсаң, Россиядә яшәүчеләрнең 12 проценты пароль буларак үзләренең өй хайваннарының, гаилә әгъзаларының исемнәрен куллана икән. Болай эшләргә ярамый! Алайга китсә, символлардан гына торган пароль күпкә тотрыклырак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН **ИЛДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕҢ 44 ПРОЦЕНТЫ КИБЕРМОШЕННИК КОРБАНЫ БУЛГАН**

65 проценты шалтыратулар кабул иткән

20–22 процентына электрон почта аша һәм социаль челтәрләрдә хатлар юлланган

36 процентына кырыгалдарлардан смс-хәбәрләр килгән

ҺӘРКЕМ БЕЛЕРГӘ ТИЕШ САНЛЫ ГАДӘТЛӘР ҺӘМ КАГЫЙДӘЛӘР

- Электрон почта аша килә торган һәр хатка, хаттагы һәр сылтамага тәнкыйди карарга, хатны ачканчы, берничә кат тикшерергә (кем җибәргән, кайдан килгән).
- Вирустан саклаучы җайланмалар кулланырга.
- Банк картасындагы исәп-хисап эшләрен күзәтеп торырга, шикләндерә торган гамәлләр булса, банкка мөрәҗәгать итәргә.
- Гаджеттагы операцион системаны, кушымталарны даими рәвештә яңартып торырга (обновление).
- «Двухфакторная аутентификация» функциясен кулланырга.
- Күп кенә социаль челтәрләрдә «Настройки» өлешендә «конфиденциальность» дигән бүлек табарга була. Аннан файдаланырга.
- Киберһөҗүмгә каршы торырлык ышанычлы пароль кулланырга.
- Ниндидер кушымта йөкләтергә кирәк икән, аны бары тик рәсми сайт, рәсми интернет-кибеттән генә алырга.
- Якын кешеләрегез җибәргән сылтамаларга да шикләнеп карарга, шундук аларны ачмаска, сылтамалар аша узмаска.
- Нинди дә булса сайтка керер алдыннан, анда акчалата эш башкарганчы, сайт адресын тикшерегез. URL адрес шик тудырырга тиеш түгел. Әйтик, анда орфографик хаталар юкмы, сайтның дизайны шик тудырмыймы – башта тикшерегез.
- Интернетта үзегез турында артык күп мәгълүмат белән бүлешмәгез. Әйтик, өй адресы, балагыз укыган мәктәп, шәхси номерларыгызны анда күрсәтү кирәк түгел.
- Банк картасына кагылышлы мәгълүматны сайтларда, түләү башкарылган интернет-хезмәтләрнең «хәтер»ендә сакларга калдырмагыз.

26 февраль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Дуслык иленда» 12+
16.15 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.15 «Татарстан без коррупции» 16+
18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
18.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Адмирал» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Җырлыйк әле!» 12+
01.40 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.50 «В стране дружбы» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Сәләт» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
22.55 «Большая игра» 16+
00.00 «Александр Проханов. Исповедь» 18+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 Выборы Президента России-2024. Дебаты
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «Наши» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.55 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 17.50 Новости
07.05, 21.50, 00.45 Все на Матч!
10.05 «Лица страны» 12+
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10 «Магия большого спорта» 12+
11.40 Еврофутбол. Обзор 6+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!»
14.20 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
15.25 «Громко»
16.40 «Фабрика грёз: Бенфика» 12+
17.55 Наши в UFC 16+
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» Москва – ЦСКА
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Лацио»
01.30 Художественная гимнастика. Гала-концерт 6+
03.25 Фрирайд. Мировой тур 6+
04.00 Лёгкая атлетика. Чемпионат России в закрытых помещениях 6+

НТВ

04.55 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ГДР» 16+
22.10 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. НОВЫЕ ГОРИЗОНТЫ» 12+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024»
«ОДИН ПРОТИВ ВСЕХ» 16+
03.20 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25, 04.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 02.50 «Тест на отцовство» 16+
10.40. 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ПАУЧИЙ ИСТОЧНИК» 16+
05.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «ДУЭЛЯНТ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.20 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЕД!» 12+
12.40, 13.25, 03.30 «БЫВШИХ НЕ БЫВАЕТ» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.55 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
02.35 «Автомобили в погонах» 16+

27 февраль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара»16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
00.40 «Башваткыч» 12+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
07.45 Выборы-2024
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 Выборы Президента России-2024. Дебаты
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.55 «Кто кого?» 12+
06.30 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 17.50 Новости
07.05, 15.25, 19.25, 22.35, 01.30 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10 «Магия большого спорта» 12+
11.40 Бокс. Bare Knuckle FC. Станислав Гросу против Брэндона Шейверса 16+
13.00 «Есть тема!»
14.20 «Что за спорт?» 12+
16.40 «Фабрика грёз: Бенфика» 12+
17.55 Смешанные единоборства. UFC. Брэндон Морено против Брэндона Ройвала 16+
19.55 «Финт Боброва» 12+
23.25 Футбол. Кубок Испании. 1/2 финала
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Кузбасс» – «Динамо» 6+
04.00 Лёгкая атлетика. Мировой тур в закрытых помещениях 6+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ГДР» 16+
22.10 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. НОВЫЕ ГОРИЗОНТЫ» 12+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «ОДИН ПРОТИВ ВСЕХ» 16+
03.10 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 04.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 02.50 «Тест на отцовство» 16+
10.40. 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «Я НЕ ТВОЯ» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «БЫВШИХ НЕ БЫВАЕТ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.20 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЕД!» 12+
12.35, 13.25, 03.35 «СТАРОЕ РУЖЬЕ» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.55 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
02.30 «Автомобили в погонах» 16+
03.15 «Москва фронту» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың сәнәгать потенциалын ныгытуга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Казанның «Союз» тәҗрибә конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: генераль директорның беренче урынбасары **Галиев** Рафаэль Мансур улы, генераль директорның инвестиция проектлары буенча ярдәмчесе **Гыйльметдинов** Мансур Шәйхетдин улы, техник контроль бүлегенең магнит һәм ультратавыш контроле дефектоскописты **Тюменева** Наилә Мөхәммәтҗан кызы, 01 конструкторлык бүлеге әйдәүче инженеры-конструкторы **Хәлиуллина** Лариса Алексеевна; хезмәтендә уңышларга ирешүе, күп еллар дәвамында нәтиҗәле эшләве һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен «Россия инновация ягулык-энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең мобилизация һәм махсус эш бүлеге махсус эш инженеры, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы депутаты **Әгълиуллина** Гүзәл Дамир кызы; Татарстан Республикасында милләтләр арасында тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга зур өлеш кертүе, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы «Демос» грекларның милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Анастасов** Георгий Николаевич; эчке эшләр органнары өчен квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесенең оператив-эзләү эшчәнлеге кафедрасы укытучысы, отставкадагы полиция подполковнигы **Макаров** Александр Семенович; хезмәтләрендә нәтиҗәләргә ирешүләре һәм күп еллар дәвамында намус белән эшләүләре өчен Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының социаль тәэминат үзәге башлыгы **Сәлахов** Эдуард Әнәс улы, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казанның Жуков орденлы Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесенең элемтә узелы (автоматлаштырылган) станциясе башлыгы **Стяжкина** Сания Вазыйх кызы, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казанның Жуков орденлы Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесе төркем (мобилизацион кучешне тәэмин итү) башлыгының өлкән ярдәмчесе **Шаймарданов** Әскәр Рөстәм улын; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең финанс идарәсе башлыгы урынбасары **Яковлева** Светлана Азат кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераннары: **Абдуллин** Зөфәр Нурмөхәммәт улы, **Вагыйзова** Зәбидә Мөхәммәт кызы, **Малафеев** Александр Васильевич, **Рәимов** Надир Назиб улы, **Шпагин** Игорь Петрович; җәмгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераннары: **Мөхәммәтшин** Насыйр Латыйп улы, **Фатыйхов** Шамил Закир улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

ЯЗГЫ КЫТЛЫК

vk.com

Авитаминоз галәмәте! Яз җиттеме, ике көннең берендә шул сүзне ишетергә туры килә. Хәл булмаса да, авырып китсәк тә, язгы чорда барын да организмга витаминнар җитмәүгә сылтыйбыз. Болай эшләү дөресме? Организм витаминнарга кытлык кичермәсен өчен ни эшләргә?



Табиб-терапевт Ләйсән ФӘТКУЛЛИНА белән шул хакта сөйләштек.

:: Витамин җитмәү чорына аяк басабыз. Без бу халәт турында ниләр белеп торырга тиеш?

– Авитаминоз – теге яки бу витаминның организмда бөтенләй булмавы. Бүгенге шартларда бу хәл бөтенләй мөмкин түгел, билгеле. Шуңа күрә соңгы елларда «авитаминоз» дигән төшенчә бөтенләй кулланылмый диярлек. Организмга витаминнар җитмәү турында сөйләгәндә гиповитаминозны күздә тотабыз. Анысы организмда теге яки бу витаминның бик аз булуын аңлата. Гиповитаминозның билгеләре аермачык күзгә ташланмый, яшерен рәвештә уза. Организмына билгеле бер төр витамин җитмәгән кеше хәлсезлектән интегә, игътибарсызга әйләнә. Ул тиз арый, эшкә кулы ятмый, йокы режимы бозыла, тырнаклары сына, чәче коела. Андый чакта организм инфекцияләргә дә каршы тора алмый.

:: Ә менә кайсы витамин җитмәгәнне нинди билгеләр буенча төгәл ачыклап буламы?

– Организмга кайсы витамин, минераллар җитмәгәнне тышкы билгеләр буенча гына ачыклап бетереп булмый. Алар бер-берсенә бик нык охшаш. Шулай да тәҗрибәмнән чыгып, шунысын төгәл әйтә алам: бүген күбебезнең организмына D, A, E, C витаминнары, B төркеменә кергән витаминнар җитми. Безнең төбәктә яшәүчеләр йод, кальций, магний, цинк, тимер, селен кебек минераль матдәләргә дә кытлык кичерә. Алар барысы да табиб киңәше буенча гына кабул ителергә тиеш. Организмга конкрет кайсы витаминның җитмәгәнен күрсәтүче махсус биохимик анализлар бар. Шулай да витаминнар җитмәүне комплекслы анализ ярдәмендә ачыклау хәерлерәк.

:: Яшерен-батырын түгел: без ел дәвамында витаминын да эчәбез, ризыгыбыз да гел төрләнеп тора. Шулай да организм барыбер витаминнарга кытлык кичерә. Бу ни сәбәпле килеп чыга икән?

– Организмга теге яки бу витамин җитмәү иң беренче чиратта дөрес тукланмауга бәйле. Кеше даими стресслар кичереп, исерткеч эчемлекләр кулланып, тәмәке тартып, фастфуд кебек зыянлы, майлы ризыклар ашап, организмны ни дәрәҗәдә җимерүен күз алдына да китерми. Аннары: «Нигә шулай еш авырыйм икән?» – дип баш ватабыз.

:: Организм витаминнарга кытлык кичермәсен өчен, нинди киңәшләрне истә тотарга кирәк?

– Әйткәнемчә, ашаган ризыгыбыз – иң төп витаминнар чыганагы. Шуңа күрә гиповитаминозны булдырмыйм дисәң, дөрес тукланырга кирәк. Әмма шунысын да истән чыгармагыз: ашказаны, эчәк авырулары булган кешеләр ризык ярдәмендә витамин туплый алмый. Андый чакта организм ризыктагы витаминнарны үзләштерергә сәләтсез була. Тагын шунысы да бар: витаминнар организмда запас булып җыелып ятмый. Алар безгә гел кирәк. Шуңа күрә организмыгызны витаминнар белән гел баетып торырга онытмагыз.

НИНДИ ВИТАМИН ҖИТМИ?

Витамин	Витамин җитмәү билгесе	Витамин иң күп булган продуктлар
D витамины	Чәч-тырнаклар сыну, тән тиресе бетчәләү, битарафлык, кәефсезлек, нык тирләү (зурлар гына түгел, балалар да).	Балык мае, кызыл балык, йомырка сарысы, кызыл һәм кара уылдык, майлы сырлар, кәҗә сөте, әтәч гөмбәсе.
А витамины (ретинол)	Томау төшү, борын тыгылу, тән тиресе кипшену, чәчләр сыну, күзләрнең күрү сәләте начараю, тырнаклар катламлану, еш суык тию.	Кишер, кабак, татлы кызыл борыч, абрикос, тавык бавыры, тәрәч бавыры, майлы сырлар, атланмай, эремчек, пастеризацияләнмәгән сөт.
Е витамины	Хәлсезлек, тиз ару, мускуллар авырту.	Үсемлек мае, җир чикләвеге (арахис), бадәм (миндаль), урман чикләвеге, зәйтүн җимеше, авокадо.
B_1 витамины	Хәтер начараю, тиз ару, баш авырту, колак чыңлау, аяк-кул оюы.	Эрбет, пестә (фисташка), җир чикләвекләре, көнбагыш, борчак, соллы көрпәсе.
B_{12} витамины	Аяк-кул оюы-чәнчешү, баш әйләнү, хәлсезлек, укшыту, тән тиресе төссезләнү, аппетит булмау, хатын-кызларда – күрем циклы бозылу.	Сыер бавыры, диңгез продуктлары, сарык ите, тунец, скумбрия балыклары, сыер ите, йомырка, каты сырлар.
С витамины (аскорбин кислотасы)	Томау төшү, борын тыгылу, иммунитет йомшару, уртлар канау, еш салкын тию, тән тиресе кипшену.	Гөлҗимеш, сырганак, татлы борыч, киви, укроп, кара карлыган, брюссель кәбестәсе, әфлисун.
К витамины	Борын канау, җәрәхәт начар төзәлү, уртлар канау, юан эчәктән кан килү.	Петрушка, кресс-салат, шпинат, кинза, эрбет чикләвеге, рәйхан (базилик), кәбестә.
РР витамины (никотин кислотасы, B_3 витамины)	Эч китү, тән тиресе бозылу, аппетит югалу, хәлсезлек, сару кайнау, йокысызлык, укшыту.	Ак гөмбә, җир чикләвеге, көнбагыш, борчак, йомырка порошогы, сыер бавыры, тунец, күрәгә.
Тимер	Хәлсезлек, тән тиресе төссезләнү, тиз алҗу, колак чыңлау, сулыш кысылу, хәтер начараю, аппетит югалу.	Кәнҗәт, диңгез кәбестәсе, бодай көрпәсе, җир чикләвеге, борчак, йомырка порошогы, күрәгә, гөмбә.
Цинк	Томау төшү, борын тыгылу, тәм һәм ис сизүнең начараюы, баш кавыклау, тән тиресе бетчәләү.	Бодай көрпәсе, эрбет чикләвеге, борчак, көнбагыш, Голландия сыры, йомырка порошогы, сарык ите.

Абау!

Тузан симертә!

Балаларның артык авырлыктан интегүенә тузан гаепле! Американың Дьюк университеты галимнәре шундый шаккатыргыч белдерү ясаган. Галимнәр фикеренчә, өйдә анда-санда күзгә чалынган тузан составындагы матдәләр организмда май туплануга этәргеч бирә. «Шуңа күрә хәзер Җир йөзендәге һәр биш баланың берсе – артык авырлыктан, һәр егерме баланың берсе симерүдән интегә», – ди алар.

Фастфуд башына җиткән

Британиядә яшәүче бер яшүсмер чипсы һәм сосиска гына ашап торуы аркасында сукырайган. Ул гына да түгел, күптән түгел егет начар ишетә башлавыннан да зарланган. Яшүсмер ун ел дәвамында үзенчәлекле диетада утырган. Ул яшелчә, җиләк-җимештән тулысынча баш тартып, чипсы, сосиска, фри бәрәңгесе кебек ярымфабрикатлар гына ашап торган. Ахыр чиктә, 15 яшьлек малай күзе начар күрү, колагы начар ишетүдән зарлана башлый. Табиб малайга B_{12} витамины кадатырга, туклану рәвешен тулысынча үзгәртергә куша. Ләкин яшүсмер бу сүзләргә колак салмый, элеккечә үк үзгә диетада утыруын дәвам итә. Ике елдан исә ул тулысынча сукырая. Хәзер егеткә – 19 яшь. Ул төрле витамин һәм минераллардан торган препаратлар эчә башлаган. Табиблар исә: «Хәзер инде дару эчүдән файда юк. Фастфуд кына ашап яшәгән егетнең күз нервы шул дәрәҗәдә эштән чыккан ки, хәзер инде ул гомерлеккә сукыр калачак», – дигән.

Үзем сынадым

ХӘЛ КЕРТӘ

Язгы хәлсезлектән гөлҗимеш, кычыткан, тукранбаш төнәтмәсе эчәргә була. Суган, сарымсак ашау, бал суы эчү дә файдалы. Иммунитетны ныгыта торган төнәтмәләр дә эчсәң була. Ләкин аны көздән үк эчә башларга кирәк. Андый төнәтмәләрне үзебездә үсмәгән үләннәрне читтән алдырып, бездәгеләре белән кушып ясыйм. Организмны витаминнарга баета торган төнәтмәне исә һәркем ясый ала. Блендерда вакланган 10 тырнак сарымсакны бал белән кушып, суыткычта сакларга кирәк. Шуны көнгә 1 аш кашыгы кабасы.

Гөлчирә НӘҖМЕТДИНОВА.
Арча районы Наласа авылы

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

Чәчәр вакыт

Бакчачылар өчен җаваплы чор: кыяр, помидор кебек төп яшелчә орлыкларын вакытында чәчәргә һәм сыйфатлы, нык кәлшәләр үстерергә кирәк. Укучыларыбызга агроном Николай РОГОВЦЕВ киңәшләре файдага булыр.

vk.com

Соңламаска

Татлы борыч һәм баклажанны февраль аенда чәчәргә өлгермәсәгез, март башында да соң түгел. Ә инде ай дәвамында помидор, иртә өлгерешле гадәти кәбестә, төсле кәбестә, физалис, порей суганы орлыкларын туфракка кертергә кирәк.

Җылы тәрәзә

Бакчачыларның күпчелеге кәлшәне тәрәзә төбендә үстерә. Үсентеләрнең тамырлары җылылык таләп иткәнлектән, орлык чәчелгән савытны тәрәзә төбенә катыргы, иске журнал яисә пенопласт куеп, шуның өстенә утыртсагыз яхшы.

Үсенте өчен иң әйбәте – көньяк, көньяк-көнбатыш яки көньяк-көнчыгышка карап торган тәрәзәләр. Чөнки яктылык күп төшә. Ә менә төньяк, төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш юнәлешендәге тәрәзә төпләрендә үсентеләр өстәмә яктылык таләп итә. Яктылык җитмәсә, үсенте, нечкәреп, биек булып үсә, уңышы да яхшы булмый. Шунлыктан фитолампа кулланырга кирәк. Люминесцент яки светодиодлы лампалар да кулланырга ярый.

Тере су кирәк

Үсентеләргә суны краннан агызып алуга сибәргә ярамый. Зарарлы матдәләре парга әйләнеп бетсен өчен, савытка салып, 12–24 сәгать тотарга кирәк. Ә иң яхшысы – чишмә яки кар суы.

Шәһәрдә кар пычрак булганлыктан, аны эретүдән мәгънә юк. Әмма яхшы сулы булуның бер яхшы ысулы бар. Калада яшәүчеләргә, чиста суга ия булу өчен, краннан аккан судан файдаланырга мөмкин. Суны савытка салып тотканнан соң 2–3 сәгатькә суыкка чыгаралар. Өстендә һәм савыт кырыйларында юка боз пәйда булгач, суны башка савытка бушаталар да тагын суыкка куялар. 2/3 өлеше катып, бозга әйләнгәч, суын түгеп, бозын бүлмә температурасында эретәләр. Чын мәгънәсендәге тере кар-боз суы булачак бу!

Караяктан саклан

Тәрәзә төбендәге кәлшәләр өчен иң куркыныч «дошман» – караяк. Гөмбәчек авыруы сабакның түбәнге өлешен нечкәртеп, каралта. Нәтиҗәдә үсенте корый. Гадәттә кәлшәләр куе утыртылганда, салкын су сипкәндә, бүлмә температурасы кинәт алышынганда шулай була. Чирнең беренче билгеләре күренүгә, зарарланган үсентеләрне тамыры белән йолкып ташларга, калганнарына җылы (+22...+25 градус) марганцовка эремәсе салынган су (10 л суга 3 г) сибәргә кирәк. Шуннан соң туфрак өстенә кыздырылган ком (суынгач, 1–2 см калынлыкта) яки ком белән көл катнашмасы (1:1) сибәргә.

Агачлар авырмасын

Агачларны корткычлардан саклау – соңрак башкарыла торган эш. Бөреләре күренә башлаганчы, тәүлеклек уртача температура +4 градус чамасы торганда, җимеш агачлары һәм куакларына 3 процентлы бордо эремәсе яки 4–5 процентлы мочевина (аммиак селитрасы) эремәсе бөркергә онытмагыз. Ботакларда кышлаган корткычлардан, гөмбәчек авыруларыннан шулай гына котылырга мөмкин.

Ә инде карлыган һәм крыжовник куакларына лейкадан кайнар су (80 градустан ким булмаска тиеш) бөркиләр. Болай эшләгәндә, үлән бете, карлыган талпаны күкәйләре юкка чыгачак һәм куаклар җиңел сулып куячак.

Тәмле булсын!

Беленнән – торт

Роза НИЗАМОВА рецепты

«Һәр ел саен 23 февральдә гаиләмдәге ир-атларны шундый торт белән сыйлыйм. Бик гади ич бу, бәйрәмчә түгел, дияргә ашыкмагыз. Ирләргә купшылык әлләни кирәкми, алар өчен иң мөһиме – ризыкның тәмле һәм туклыклы булуы. Тортны, һәрбер катына варенье, бал, куертылган сөт сылап, татлы эчлек белән ясарга мөмкин. Эчлек өчен яшелчә, сыр, ит яки балык куллансаң да әйбәт булачак», – ди Роза ханым.

Кирәк: 6–7 юка белен, 200 г йомшак сыр («сливочный»), 200 г чикләвекле ит (итне ваклап турыйбыз һәм төелгән чикләвек өстәп болгатабыз), өстен бизәү өчен яшел тәмләткеч.

Юка гына итеп беленнәр пешерәбез. Зур ясcы тәлинкәдә торт ясыйбыз. Иң астагы беленгә сыр сылыйбыз. Өстенә икенчесен куеп, чикләвекле итне тигез итеп җәябез. Шул рәвешле сырлы-итле катламнарны чиратлаштырып, торт ясыйбыз. Өстен ваклап туралган укроп, петрушка яфраклары белән бизибез.

Белеп тор!

Арзанга чыга

Савыт-саба юу өчен «Фейри» сыекчасын иң яхшысы дип мактыйлар. Ләкин ул кыйммәтрәк. Акчаны янга калдыру өчен, аның урынына арзанлысын гына сатып алырга да шуңа берничә аш кашыгы серкә өстәргә мөмкин. Тәлинкәләр яңа гына кибеттән сатып алынган кебек ялтырап торачак!

Линолеумны тигезләү

Кабарып торган, яньчелгән урыннарын тигезләү өчен, линолеумның өстенә кайнар сулы (әмма бик кайнар булырга тиеш) кәстрүл куеп торырга кирәк. Болай эшләгәндә, идән тип-тигез калачак.

Алтынны юу сере

Алтыннан эшләнгән бизәнү әйберләрен юу-чистартуның иң гади ысулын беләсезме икән? Алка-йөзекләрне җепкә тезеп, ике очын бергә бәйләп куябыз да (таралып китмәсеннәр өчен) сулы кәстрүлгә салабыз. 1 чәй кашыгы теләсә нинди кер порошогы өстибез. Биш минут тотабыз. Чиста суда чайкагач, сөлгегә салып киптерәбез. Алтын әйберләр кибет киштәсендәге кебек ялт итеп торачак.

Исеңдә тот!

Битне сөртмә!

Яшь барган саен, тән тиресе кипшенә. Шуңа күрә җыерчыклар барлыкка килә.

Косметологлар киңәш иткәнчә, иртән һәм кичен битне юганнан соң, сөлге белән сөртенмичә, дымлы тирегә тукландыргыч крем сөртергә кирәк. Әмма сеңдерерлек итеп түгел, бәлки саклык белән, җиңелчә генә. Бит, су белән кремны «эчеп», үзеннән-үзе кибәргә тиеш.

Болай эшләгәндә бит тиресе бик озак яшь булып калачак.

Укучы киңәше

Кокос кабыгында үстерәм

Кәлшә үстерү өчен инде байтактан кокос субстраты кулланам. Бик уңайлы: 5 килолы брикеттан 65–70 л туфрак әзерләргә мөмкин. Өстәвенә бик йомшак, ябышмый, катмый һәм дымны озак саклый. Аны башта зур савытка салып, өстенә кайнар су агызам. 20 минуттан соң, бүртеп, туфракка әйләнә ул.

Кыяр, кабак ише эре орлыклы культураларны тишелдергәндә кокоска башка әйбер кушмыйм. Ә менә томат, татлы борыч, чәчәк кебек вак орлыклылары өчен 1:1 нисбәтендә торф өстим. Кучерепп утырту өчен туфрак әзерләгәндә исә, 1 өлеш кокос грунтына 2 өлеш торф кушам. Татлы борыч һәм кыяр өчен әле тагын бер өлеш биогумус та өстәп җибәрәм.

Кәлшәләрне, берни өстәмичә, шул кокос грунтында гына үстергәнем дә бар. Әмма торфлы катнашмада үстерү миңа күбрәк ошый.

Гөлфия НУРГАЛИЕВА. Казан

Нашатырь булыша

Нашатырь спиртын кыяр үсентесе, яран гөле бик ярата. 4 литр суга 50 мл нашатырь спирты салып эретәм дә үсемлекләргә шуны «эчертәм». Үсентеләрне тукландыру белән берррәттән, бүлмәдәге чит исләрне, черкиләрне дә юкка чыгару өчен менә дигән ысул.

Сәвия ГАЛИУЛЛИНА. Балык Бистәсе

БАБАЙ ТҮГЕЛ

Ходай, Аллаһы Тәгалә, Алла бабай... Бөек Раббыбызны әнә шулай төрлечә атарга өйрәнгән без. Аларның барысын да куллану хәерлеме? «Алла бабай» дигән сүз ни өчен бәхәсләр уята?

Бу сорауларга Мөхәммәт хәзрәт МИФТАХОВ ачыклык кертте.

:: Хәзрәт, без кечкенәдән Ходайны Алла бабай дип ишетеп үстек. Беренче карашка, бик җиңел истә калса да, икенче яктан, бөек Раббыбызны гадиләтә төшкән кебек бу исем. Бу уңайдан сезнең фикерне дә ишетәсе килә.

– Җәннәтне ничек кенә күзалларга тырышсак та, чынлыкта ул без уйлаганнан да матуррак, ләззәтлерәк. Без иң яхшы дип уйлаган тормыш җәннәткә якын да килми. Аллаһы Тәгаләнең безгә җәннәт турындагы хәбәрләреннән шул аңлашыла. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Бу дөньяда бер кеше булган. Аз күлгән, аз елмайган, тормышта бик күп авырлыклар күргән. Әмма гамәлләре белән җәннәткә лаек булган ул. Аны бер мизгелгә җәннәткә кертәләр. Аннан чыккач, бу кешедән: «Син җәннәттә берәр авырлык күрдеңме?» – дип сорыйлар. Ул: «Юк, күрмәдем», – дип җавап бирә. Җәннәттә булган бер мизгел бөтен авырлыкны сөртеп юкка чыгара. Тагын бер хәдистән аңлашылганча, җәннәт әһелләре Аллаһы Тәгаләне күргәч, җәннәттә булган бөтен ләззәтләрне онытачак. Ягъни Раббыбыз шул дәрәҗәдә матур. Шуңа күрә халыкта, бигрәк тә авыл җирләрендә таралган «Алла бабай» дигән сүз динебезгә туры килми. Ул нинди бабай булсын ди? Аллаһы Тәгаләгә кеше төсмерләре тагу динебездә тыела. Шуңа күрә кеше, белә торып, «Алла бабай» дип әйтә икән, ул динне боза дигән сүз. Коръәни Кәримдә: «Аллаһ беркемгә дә, бернәрсәгә дә охшамаган», – диелә. Ягъни безгә Аллаһы Тәгаләне күз алдына китерергә ярамый. Моңа рөхсәт юк. Ник дигәндә, кеше беркайчан күрмәгән нәрсәне күз алдына китерә алмый.

:: «Алла бабай» сүзен, гадәттә, балаларга Ходай Тәгаләнең кем икәнен аңлатканда кулланалар. «Алла бабай бар, ул безнең бөтен гамәлләрне өстән карап тора», – дип сөйлиләр, гадәттә. Бабай сүзен ишеткәч, бала аны яхшырак аңлый, истә калдыра кебек...

– Алай дип аңлатсаң, бала яхшырак истә калдыра дип уйлаучы ата-аналар ялгыша. Чынлыкта, балаларга барысын да ничек бар, шулай сөйләргә кирәк. Алар барысын да бик яхшы аңлый. Аллаһы Тәгалә, Раббыбыз дип сөйләсәң дә, барысын да истә калдырачаклар. Без балаларга кешелекне кем яралтканны, Аллаһы Тәгаләнең кемлеген яхшылап аңлатырга тиеш. Балага нәрсәнедер аңлатканда да чикләр бар. Без бу очракта да тыелган нәрсәләргә керә алмыйбыз. Балаларны да шуңа өйрәтергә кирәк.

islam.ru

:: Машинага, футболкага, савыт-сабага «Алла сакласын», «Аллаһы Тәгалә» дигән сүзләр язу дөресме?

– Әгәр мондый савыт-саба сувенир буларак кына кулланылса, моның бер зыяны да юк. Әмма «Аллаһы Тәгалә» дип язылган савыт-сабаны ашау-эчү өчен куллану дөрес булмас. Ник дигәндә, ул пычрана һәм юганда да пычрак савыт-саба белән бергә юыла. Шуңа күрә мондый савыт-саба Аллаһы Тәгалә турында искә төшерүче зикер сыйфатында киштәдә генә торырга тиеш. Кием белән дә шул ук хәл. Шул ук футболканы юдырганда да ул кер машинасына пычрак керләр белән бергә салынырга мөмкин. Шуңа күрә «Аллаһ» исеме язылган кием, кулланылмыйча, сувенир рәвешендә торса гына яхшы. Машинага да «Алла сакласын», «Аллаһы Тәгалә» кебек сүзләр язу киңәш ителми.

:: Аллаһы Тәгалә белән ант итәргә ярыймы?

– Мөселманга нәкъ менә Аллаһы Тәгалә белән генә ант итү рөхсәт ителгән дә инде. Башка әйберләр белән, әйтик, әти-әни, балалар, китап һ.б. белән ант итү ширек була. Ә менә Аллаһы Тәгалә – безне яралтучы. Ул кем белән, нәрсә белән тели, шуның белән ант итә ала.

Март аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Жом	04:30	06:33	15:21	17:18	19:00
2	Шим	04:28	06:31	15:23	17:20	19:02
3	Якш	04:25	06:28	15:24	17:22	19:04
4	Дүш	04:23	06:26	15:26	17:25	19:06
5	Сиш	04:20	06:23	15:28	17:27	19:08
6	Чәрш	04:18	06:21	15:30	17:29	19:10
7	Пәнҗ	04:15	06:18	15:32	17:31	19:12
8	Жом	04:12	06:16	15:33	17:33	19:14
9	Шим	04:09	06:13	15:35	17:35	19:17
10	Якш	04:07	06:10	15:37	17:37	19:19
11	Дүш	04:04	06:08	15:39	17:39	19:21
12	Сиш	04:01	06:05	15:40	17:41	19:23
13	Чәрш	03:58	06:03	15:42	17:43	19:25
14	Пәнҗ	03:55	06:00	15:44	17:45	19:28
15	Жом	03:52	05:57	15:45	17:47	19:30
16	Шим	03:49	05:55	15:47	17:49	19:32
17	Якш	03:46	05:52	15:49	17:51	19:34
18	Дүш	03:43	05:50	15:50	17:53	19:37
19	Сиш	03:40	05:47	15:52	17:55	19:39
20	Чәрш	03:37	05:44	15:54	17:58	19:41
21	Пәнҗ	03:34	05:42	15:55	18:00	19:44
22	Жом	03:31	05:39	15:57	18:02	19:46
23	Шим	03:28	05:37	15:58	18:04	19:48
24	Якш	03:25	05:34	16:00	18:06	19:51
25	Дүш	03:22	05:31	16:02	18:08	19:53
26	Сиш	03:18	05:29	16:03	18:10	19:56
27	Чәрш	03:15	05:26	16:05	18:12	19:58
28	Пәнҗ	03:12	05:23	16:06	18:14	20:01
29	Жом	03:09	05:21	16:08	18:16	20:03
30	Шим	03:05	05:18	16:09	18:18	20:06
31	Якш	03:02	05:16	16:11	18:20	20:08

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Гыйбрәт ал!

Нәтиҗә алдан йөрмәсен!

Көннәрдән бер көнне ике күрше балаларына йорт хайваны сатып алган. Берсе баласына – эт, икенчесе куян бүләк иткән. Шуннан бер күрше икенчесенә:

– Синең этең безнең куянны ашап бетерәчәк бит! – дигән.

– Юк, алар әле икесе дә кечкенә. Яшьтән бергә уйнап үсәләр, дуслашырлар, берни булмас, – дигән күршесе.

Шулай килеп чыга да. Эт белән куян баласы бик тиз уртак тел таба. Дус-тату булып, бергә уйнап үсәләр. Этнең – куян янына, куянның эт янына кунакка йөрүе гадәти күренешкә әверелгән.

Көннәрдән бер көнне куянның хуҗалары кунакка китә. Төш турысында күршеләрнең алагаем зур этләре, авызына канга баткан, йолкынган, балчыкка буялып беткән куян баласын кабып кайтып керә. Хуҗалары аптырап кала. Гаилә башлыгы шундук: «Мин шулай булачак дип алдан ук кисәттем бит. Ник үтердең?» – дип этне әрләргә тотына. Эт исә күз яшьләрен тыя алмыйча, үкси-үкси, куянның канлы яраларын ялавын белә.

Хуҗалар, күршеләре кайтканчы, куянны юып, киптереп, йоклап яткан рәвештә оясына илтеп салалар. Күп тә үтми кунакка киткән күршеләр дә кайтып җитә. Ике минуттан инде куянның хуҗасы күршеләрнең ишеген шакый.

– Нәрсә булды? Ник агарындың? – дип сорый эт хуҗасы.

– Безнең куян... Куян... – ди күршесе, тын да ала алмыйча.

– Үлгәнме? Әле бүген көндез генә сикереп йөри иде бит.

– Юк, үлүен җомга көнне үк үлгән иде. Без китәр алдыннан балалар аны бакча артына күмеп куйган иде. Кайтсак, куяныбыз исән! Берни булмагандай үз оясында ята! – дип шаккаткан хуҗа кеше.

Баксаң, җомга көннән бирле балачак дустын эзләгән эт, аны, ниһаять, табып, казып алып, коткару өчен хуҗаларына илткән икән. Беркайчан да эшнең нидә икәнлеген төгәен ачыкламыйча, ашыгыч нәтиҗәләр ясарга ярамый шул.

***

Кешеләр турында берниндигез сез яман уйлаудан сакланыгыз, чөнки начар уй – сүзләрнең иң ялганы. Кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, көнләшмәгез, ачуланышмагыз, бер-берегезне ташламагыз, Аллаһының коллары булган хәлдә бер-берегезгә кардәшләр булыгыз! (Хәдис)

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Бер сүз җитә

Уйламый әйтелгәне дә, әйтелми калганы да куркыныч. Сүзнең көче дә, тәэсире дә зур – моны һәркем белә, әмма кайчак тиешенчә бәяләми. Сәхифәбездәге яңа сорау – җавап та тормыштагы әһәмиятле сүзләргә багышлана. Бу юлы без юмор остасы, алып баручы Әбри ХӘБРИЕВ белән сөйләштек.

:: Иң кадерле сүз?
– Сәламәтлек.

:: Бирешкәндә тартып торгызган сүз?
– Булдырасың.

:: Бик каты яралаган, рәнҗеткән сүз?
– Кылый (балачак хатирәләреннән, хәзер иләндем инде).

:: Әйтәсе килеп тә, әйтә алмый калган сүз?
– Ой, күп андый сүзләр.

:: Бүген, хәзер ишетәсе килгән сүз?
– Бүген андый таләпләр юк дисәң дә була.

Аннан-моннан

Узып баручы атна нилəр белән истә калачак? Бу сорауга җавап итеп, социаль челтәрләрдәге «кайнар» яңалыкларны тупладык.

Илнар Сәйфиев ябыгуының серен ачты. Озак кына югалып торган җырчы сәхнәгә шактый үзгәреп чыкты. Аның ябыгуына игътибар итмәүчеләр аз булгандыр. Илнар сүзләренчә, ябыгуының төп сере – дөрес туклану. Җырчы социаль челтәрләрдә шуңа багышланган яңа сәхифә дә ачкан.

Алсу Фазлыева ни сәбәпле концертларда катнашмый? Җырчы бу сорауга социаль челтәрләрнең берсендә җавап биргән. Төп сәбәбе – балалар. «Мин хәзер үземне балаларга багышладым һәм алар белән күбрәк шөгыльләнә башладым. Мин өйдә торгач, балалар күзгә күренеп ачыла», – ди Алсу.

Данир Сабиров баткан. Гаҗәпләнмәгез, әмма социаль челтәрләрдә шактый кызыксыну уяткан яңалык бу. Концерт куеп, Актаныштан Казанга кайтканда, юмор остасы төркеме белән батып калган. «Булдыра алганча тырыштык. Бик авыр булды, ләкин бирешмәдек, җаен таптык», – ди Данир. Шулай итә-итә, башкалага иртәнге җидедә кайтып җиткән алар.

Илсөя Бәдретдинова китап язачак. Берәр кайчан. Социаль челтәрләрендә балачагы турында хатирәләргә бирелгәндә, җырчы әнә шулай диде. «Тәрлесе булды, бер генә көн булса да төрмәдә дә утырдым, тартып та карадым. Шашып яраттым! Сикерәм, дип, яр буенда акырып елаган чакларым да булды», – дигән Илсөя. Бу китапны укыр идегезме?

Миңнегалиевлар алданган туристларга акчаларын кайтара башлаган. Әлегә бөтен сумманы түгел, 500әр сумлап кына. «Без әкрен генә акчаларны кире кайтара башладык. Әлегә шулай гына», – дигән Дубайга кеше чакырып, аларны юлламасыз калдырган, ә хәзер федераль эзләүгә игълан ителгән Илүсә Миңнегалиева.

ӨЙЛӘНЕРГӘ КЕШЕ ЮК?

Бүген егетләрнең гаилә корырга ашыкмаулары берәү өчен дә сер түгел инде. Гомумән, өйләнүнең яше бармы икән ул? Акыл кергәнче өйләнергәме, акыл кергәчме? Бу юлы асыл татар буйдаклары белән әнә шул турыда сөйләштек.

Илгиз ШӘЙХРАЗИЕВ, җырчы:

Мәхәббәттән тилергән, шашып гашыйк булган, сөйгән яры тарафыннан яратылып, ярату хисләреннән исергән ир генә өйләнергә мөмкин. Аек акыл һәм үз теләге белән бу адымга бер ир дә бармый. Яратыгыз һәм үрчегез, халкым!

Динар ХӨСНЕТДИНОВ, Әлмәт театры артисты:

Һәр өйләнмәгән ир затының бу сорауга үз җавабы бардыр. Миңа килгәндә, шулай ук сәбәпләре күп. Я вакыты җитмәгән, я гаилә корырдай, балаларымның әниләре булырдай насыйп ярымны очратмаганмындыр. Аннан соң, мин – ирек сөючән кеше. Һәм, күрәсең, җаваплылыктан (ә өйләнү – җитди нәрсә) куркам.

Ренат ГАЛИӘСКӘР, шагыйрь, алып баручы:

Аллаһы Тәгаләдән вакыт җитмәүгә сылтыйм мин. Кайбер танышларымның тату гына яши алмаулары да шик кертә күңелгә. «Беркайчан да өйләнмим», – дип йөргән булмады. Хатынлы булыр өчен генә өйләнәсе килми. Матур яшисе килә. Бер тапкыр һәм яратып өйләнәсем килә!

Динар КӘРИМУЛЛИН, көрәшче, тренер:

Егетләрнең үз өсләренә җаваплылык аласылары килми, яшьрәк чакта үз-үзеңә ышану да җитеп бетмәскә мөмкин. Ныклап аякка баскач, өйләнәм дип уйлый күп егетләр. Ә еллар узган саен өйләнәсе килми, сайлана башлыйсың... Шуңа күрә яшьрәк чакта, акыл сайрак вакытта өйләнергә кирәк!

Булат ГАТАУЛЛИН, Кариев театры артисты:

Кызык сорау. Һәркемнең сәбәбе төрле дип уйлыйм. Миңа килгәндә, сәгате сукмагандыр. Эш, карьера күп вакытны ала. Ләкин соңгы арада гаиләле булу теләге арта башлады. Өйдә яраткан кешең, балаларың көтеп торудан да зур бәхет юктыр.

Артур ШӘЙДУЛЛИН, Камал театры артисты:

Кемдер карьераны беренче урынга куя. Кемнеңдер, гомумән, гаилә корырга теләге юк. «Не нагулялся», – диләр бит әле *(көлә)*. Ә мин бүген ижатка «өйләнгән». Һәм аның белән берничек тә аерылыша алмыйм. Ләкин төп сәбәбе – бер һәм бергәйле булырдай пар эзләвемдә. Танышларым арасында өйләнешеп, күпмедер вакыттан соң аерылышучылар бар. Шундый хәлгә тарымас өчен, ышанычлы кешегә өйләнәсем килә.

Бик беләсегез килсә, өйләнмәгән ир-егетләр кыскарак гомерле була икән. Бу турыда Татарстанның ЗАГС идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина әйтте. Росстат мәгълүматларына караганда, Россиядә яшәүче ир-атларның уртача гомер озынлыгы – 67 ел. «Өйләнмәгән ир-атлар, кызганыч, азрак яши, хроник авырулар белән интегә, стресска дучар була», – ди Нигъмәтуллина.

Лилия ГЫЙМАЗОВА, Ләйсән САФИНА әзерләде.

28 февраль | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара»16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Каравай» 6+
00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
01.15 «Кәмит Җавит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12++
08.30, 21.25 «Сөяем бакчасы» 16+
09.30 «Сәләт» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җавит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 Выборы Президента России-2024. Дебаты
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 17.50 Новости
07.05, 16.55, 19.25, 22.00, 00.45 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10 «Магия большого спорта» 12+
11.40 Смешанные единоборства. Анатолий Малыхин. Лучшее 16+
13.00 «Есть тема!»
14.20, 01.30 «Вид сверху» 12+
14.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Локомотив» – «Кузбасс»
17.55 Профессиональный бокс. Олег Маскаев 16+
19.55 Футбол. Чемпионат Италии
02.00 Лыжные гонки. Гонка Легкова PARI 0+
03.25 Матч! Парад 6+
04.00 Прыжки на лыжах с трамплина. Международные соревнования 6+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ГДР» 16+
22.10 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. НОВЫЕ ГОРИЗОНТЫ» 12+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «ОДИН ПРОТИВ ВСЕХ» 16+
03.10 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 04.25 «Давай разведём-ся!» 16+
08.30, 02.45 «Тест на отцовство» 16+
10.40. 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.50, 00.25 «Порча» 16+
13.00, 01.25 «Знахарка» 16+
13.35, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Кризисный центр» 16+
19.00 «БОКАЛ ВИНА И АПЕЛЬСИНЫ» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СТАРОЕ РУЖЬЕ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.00 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЕД!» 12+
12.30, 13.25, 03.30 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.55 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
02.05 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+

29 февраль | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара»16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Кәмит Җавит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Наши герои» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Ком сәгате» 16+
01.15 «Җырлыйк әле!» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җавит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
07.45 Выборы-2024
09.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию
13.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 Проект «Цивилизации» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СОЮЗ СПАСЕНИЯ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 16.00, 20.00 Вести
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию
13.00, 17.30 «60 минут» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.10 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.55 «Кто кого?» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 08.30, 14.50 Новости
07.05, 15.25, 18.45, 23.00, 01.30 Все на Матч!
08.35, 11.30 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10 Специальный репортаж 12+
13.45 «Вы это видели» 12+
14.20 «Большой хоккей» 12+
16.15, 19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
21.45 Смешанные единоборства. ACA Young Eagles
23.25 Футбол. Кубок Испании
02.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. 1/4 финала. «Виктор» – ЦСКА 6+
03.25 Матч! Парад 16+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Белогорье» – «Факел» 6+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
12.00 Послание Президента РФ Владимира Путина Федеральному Собранию
13.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ГДР» 16+
22.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. НОВЫЕ ГОРИЗОНТЫ» 12+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «Поздняков» 16+
00.45 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.50 «ОДИН ПРОТИВ ВСЕХ» 16+
03.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 04.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 02.55 «Тест на отцовство» 16+
10.40. 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.35 «Порча» 16+
13.00, 01.35 «Знахарка» 16+
13.35, 02.05 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.30 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ШАМАНКА» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10, 12.35, 13.25, 04.05 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.55 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЕД!» 12+
15.00 Военные новости 16+
17.55 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ДУМА О КОВПАКЕ» 12+
02.10 «АДМИРАЛ УШАКОВ» 12+

1 март | Җомга

ТАТАРСТАН

21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 00.05 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «ЛЮБИТЕ КУПЕРОВ» 16+
00.30 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
00.45 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Башваткыч» 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.10, 22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
03.30 «Кремль артисты» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос» 12+
23.30 «Матадор» 16+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.35, 21.15 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
15.00 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе! Хором!» 12+
00.10 «Истории Большой Страны» 12+
01.10 «ЗОРКО ЛИШЬ СЕРДЦЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 08.45, 14.50 Новости
07.05, 14.55, 21.45, 00.45 Все на Матч!
08.50 «Игры Будущего» 16+
09.35 «Небесная грация» 0+
09.55 Художественная гимнастика. Чемпионат России
15.30 Смешанные единоборства. One FC. Анатолий Малыхин против Ренье де Риддера
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. 1/8 финала
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Лацио» – «Милан»
01.30 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
02.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. 1/4 финала. «Зенит» – «СКА-Минск» 6+
03.25 Матч! Парад 16+
04.00 Бильярд. Чемпионат мира. 1/2 финала 0+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «Прошу, прости!» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ГДР» 16+
22.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. НОВЫЕ ГОРИЗОНТЫ» 12+
00.00 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.20 «Своя правда» 16+
02.10 «Квартирный вопрос» 0+
03.05 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 05.00 «Давай разведёмся!» 16+
08.25, 03.20 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.50 «Понять. Простить» 16+
11.45, 01.00 «Порча» 16+
12.55, 02.00 «Знахарка» 16+
13.30, 02.25 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.55 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «МЕЧТА НА ТРОИХ» 16+
23.25 «Уютное утро» 16+
05.50 «6 кадров» 16+
05.55 «ШАГ В БЕЗДНУ» 16+

ЗВЕЗДА

05.40 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ» 16+
08.10, 09.25 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
11.00, 13.25, 00.55 «ВИВАТ, ГАРДЕМАРИНЫ!» 12+
14.25, 15.05 «ОПЕРАЦИЯ «ТАЙФУН». ЗАДАНИЯ ОСОБОЙ ВАЖНОСТИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
03.10 «КАПИТАНСКАЯ ДОЧКА»

2 март | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 00.50 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Өмет йолдызы» 12+
16.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
17.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «КНИЖНЫЙ КЛУБ» 16+
23.45 «ПО УЛИЦАМ КОМОД ВОДИЛИ» 6+
01.15 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ» 16+
03.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00, 23.45 «Гомер тәлгәшләре» 12+
17.15 «Калеб» 6+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Аклык» 12+
22.05 З.Хәким. «Карак». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.20 «Йөрәк жылысы» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.05 «БЕЛЫЙ СНЕГ» 0+
15.30 Кубок Первого канала по фигурному катанию 2024
18.00 Вечерние новости
18.20 «Эксклюзив» 16+
20.00 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Клуб Веселых и Находчивых» 16+
23.55 «ОДИН НА ОДИН» 12+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.30 Открытие Всемирного фестиваля молодёжи 2024
23.30 «1993» 18+
02.15 «НАШЕДШЕГО ЖДЁТ ВОЗНАГРАЖДЕНИЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Заур Абдуллаев против Роджера Гутьерреса 16+
07.00, 08.30, 11.10, 13.50 Новости
07.05, 10.05, 13.15, 15.55, 22.00 Все на Матч!
08.35, 11.35 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.15 «Лица страны» 12+
13.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС – «Локомотив-Кубань»
16.15 Футбол. МИР РПЛ «Краснодар» – «Рубин»
18.30 Футбол. МИР РПЛ. «Зенит» – «Спартак»
22.40 Смешанные единоборства. UFC
02.55 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
03.25 «Вы это видели» 12+
04.00 Бильярд. Чемпионат мира 0+
05.00 Бокс. Bare Knuckle FC

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.20 «Жди меня» 12+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.10 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион» 16+
23.25 «Международная пилорама» 18+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
01.05 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Найк Борзов 16+
02.35 «Дачный ответ» 0+
03.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.35 «Уютное утро» 16+
10.00 «ОДНА ЛЮБОВЬ НА ДВОИХ» 16+
14.30 «АБРИКОСОВАЯ ГОРЕЧЬ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.50 «ДЕТИ ВЕТРА» 16+
02.25 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.20 «ДЕТИ ВЕТРА» 16+

ЗВЕЗДА

04.55 «ЗВОНЯТ, ОТКРОЙТЕ ДВЕРЬ» 6+
06.20 «ПОСЛЕ ДОЖДИЧКА, В ЧЕТВЕРГ…» 6+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.20, 03.25 «СВЕРСТНИЦЫ» 12+
11.10 «Легенды музыки» 12+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды кино» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.15 «22 МИНУТЫ» 16+
17.05, 19.25 «БИТВА ЗА МОСКВУ» 12+
01.15 «МИССИЯ В КАБУЛЕ» 12+
04.45 «Часовые памяти» 16+

3 март | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 00.35 «Риваять» төрки-татар этникасы ансамбле концерты 12+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Эти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 6+
11.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.45 «Наша республика – наше дело» 16+
14.45 «Бир кулыңны» 12+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «ЧУДЕС НЕ БЫВАЕТ» 16+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Яшик әле бу дөньяда» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 А.Цагарелли. «Ханума». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
16.10 «Бар фасылга – бер асыл» 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 «Яшик әле дөньяны яратып» 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.05 «Повара на колесах» 12+
12.15 «Большая история» 16+
13.15 «Видели видео?» 0+
15.00 Кубок Первого канала по фигурному катанию 2024
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «АБРЕК» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.20, 01.05 «ПОЛЦАРСТВА ЗА ЛЮБОВЬ» 12+
07.00 «Большие перемены»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 16.00 Вести
11.50 «НЕ ОГЛЯДЫВАЙСЯ НАЗАД» 12+
16.30 Церемония закрытия «Игр Будущего»
18.00 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ

08.00, 08.30, 11.10, 13.40 Новости
08.05, 09.55, 13.00, 22.00, 00.45 Все на Матч!
08.35, 11.50 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.15 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
13.45 Футбол. МИР РПЛ. «Пари НН» – «Факел»
16.00 Футбол. МИР РПЛ. «Динамо» – «Локомотив»
18.30 После футбола
19.30 Профессиональный бокс. Лига ставок. Ночь Чемпионов IBA
22.40 Футбол. Чемпионат Италии.
01.30 Художественная гимнастика. Чемпионат России 6+
03.25 «Что за спорт?» 12+
04.00 Бильярд. Чемпионат мира 0+

НТВ

04.50 «ПАСЕЧНИК» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.00 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
00.05 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.25 «Основано на реальных событиях» 16+
02.05 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.20 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.55 «Пять ужинов» 16+
10.10 «СЖЕЧЬ ВСЁ И НАЧАТЬ ЗАНОВО» 16+
14.40 «ВСЁ СМЕШАЛОСЬ В ДОМЕ АВДЕЕВЫХ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.50 «ШАГ В БЕЗДНУ» 16+
02.30 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+

ЗВЕЗДА

05.30, 01.50 «В ДВУХ ШАГАХ ОТ «РАЯ» 12+
07.10 «22 МИНУТЫ» 16+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Моторы и колеса» 12+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 12+
14.00 «Улика из прошлого» 16+
14.50 «Скрытые угрозы» 16+
15.40 «Секретные материалы» 16+
16.30 «Загадки века» 12+
17.20 «Специальный репортаж» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.50 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
03.20 «Перелом. Хроника Победы» 16+
03.45 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе, элекке Татарстан Республикасы Президентының Контроль идарәсе башлыгы
ЗАРИПОВ Дамир Вазыйх улының
кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисенең элекке киңәшчесе, республика дәүләт финанс контролен булдыру һәм үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән совет чорының күренекле партия, дәүләт эшлеклесе
ЗАРИПОВ Дамир Вазыйх улының
кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте ветераны, ТАССР Югары Советы Рәисе ярдәмчесе (1991), Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (1991–1998), Татарстан Республикасы Президентының контроль идарәсе җитәкчесе (1998–2004)
ЗАРИПОВ Дамир Вазыйх улының
кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Зарипов Дамир Вазыйх улының якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

«АЛЬФА»ЛАР КИЛӘЧӘГЕ

ӘЛЕГЕ БУЫННАН НӘРСӘ КӨТӘРГӘ?

«Җитеш тормыш балалары». Белгечләр әйтүенчә, илдә тәүге тапкыр әнә шундый буын үсеп җиткән. Аларга – 12–16 яшь, әзергә бәзер яшиләр, берниндι кыенлык күргәннәре юк, ә кулларыннан телефон төшми. Рәхәт, кыскасы. Тик тормыш йөген тарту алай җиңел генә түгел. Муллыкта, иркендә үскән балалардан нәрсә көтәсе? Болай булса, иртәгәге көнгә ышаныч бармы? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга җавап эзләде.

Яшерен-батырын түгел, бүгенге үсмерләр һәм яшьләрнең үз-үзен тотышыннан, без, өлкәннәрнең, кайчак чәче үрә тора. «Алар үзгә!» – бу сүзләрне әти-әниләр дә, бигрәк тә ачлык, бер телем ипине дә эшләп тапкан әби-бабайлар бик еш кабатлый. Киләчәк кем кулында? Әлеге сорауга «Платформа» үзәге социологлары җавап табарга тырышкан. Алар бер ел дәвамында 12–16 яшьлекләр арасында тикшеру үткәргән.

Әйтүләренә караганда, илдә өр-яңа буын үсеп килә. Бу – җитеш тормышта яшәүчеләр. «Алар тормышта зур үрләр яулау турында хыялланa, тик моңа әллә ни артык көч түгәргә теләми. Еш кына өлкәннәр белән уртак тел таба алмый. Шул ук вакытта, син теләгән сүзне сөйләсәләр дә, күңел халәтен сиздермиләр. Җанлы аралашуга караганда, интернетта утыруны өстенрәк күрәләр», – дигән социологлар. Сөйләп торасы да юк. Мондый иркә «гөл»ләрне үзебез үстерәбез.

– 12–16 яшьлекләр ул – «Альфа» буыны, ягъни якынча 2010 нчы еллардан соң туган балалар, – ди КФУның Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтының фәнни эшчәнлек буенча директор урынбасары, социология фәннәре докторы, социаль-сәяси фәннәре бүлеге җитәкчесе Мария Ефлова. – Әйе, аларның холкы үзенчәлекле. Беренчедән, бу – цифрлы киңлектә туган һәм үскән балалар. Алар өчен социаль чынбарлык белән цифрлы дөнья арасында тигезлек билгесе тора. Шуңа күрә цифрлы киңлектә үзләрен бик уңайлы хис итәләр. Алар белемне тиз туплый. Чөнки бүген бөтен мәгълүмат интернетта. Ә җитеш тормыш балалары гаджет белән бергә туган. Шуңа күрә кирәкле мәгълүматны бик тиз эзләп табалар. Бу балалар 20 яшькә җиткәндә үк бик белемле, мәгълүматлы булачак.

Тик тәңкәнең икенче ягы да бар.

– 12–16 яшьлекләргә чынбарлыкта шәхси, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруы авыррак. Чөнки аларның үзара аралашу күнекмәләре начар үсеш алачак. Бу күзлектән чыгып караганда, «Альфа» буыны инфантиль, ягъни җитлегеп бетмәгән. Шуңа күрә дә алар әтиәни йортыннан чыгып китәргә ашыкмаячак. Мондый балалар үзләрен яклауга мохтаҗ. Әйе, алар арасыннан галимнәр дә, сәнәгать өлкәсендә ниндидер ачыш ясаучылар да үсеп чыгачак. Әмма аларга гел ярдәм итәргә әзер булып торырга кирәк, – ди Мария Ефлова.

Артык иркәләмибезме? Бүген әле туарга өлгермәгән балага да фатирга кадәр сатып алып кую гадәти күренешкә әйләнеп бара бит. Белгечләр әйтүенчә, моны да аңлатып була.

– Чыннан да, әлеге буынның барлык беренчел ихтыяҗлары инде канәгатьләндерелгән. Аларда торак кайгысы да, ашау кайгысы да юк. 1990 нчы еллар белән чагыштырганда, ашау өчен эшлисе түгел. Шуңа күрә муллыкта үскәннәр үз тормышын бүтән социаль баскычтан башлый. Ягъни ниндидер минимал ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен көч тә, вакыт та сарыф итәргә кирәкми, – ди Мария Ефлова. – Димәк, тормышта үз урыныңны табу, эш урынында югарырак баскычка күтәрелү мөмкинлеге дә зуррак. Кемдер максатчанрак, берәүләр тыныч, икенчеләр исә ишектән кертмәсәләр, тәрәзәдән керергә әзер, әлбәттә. Сүз тулы бер буынны бәяләү турында бара.

Замана балалары ничек яши?

- Балаларның **53 проценты** гына өлкәннәр аларның сүзенә колак сала дип уйлый.
- **14 проценты** янәшәсендә таяныч булырлык өлкәннәр булмавын әйткән.
- **14 проценты**ның якын дуслары юк.
- **18 проценты** ялгызлык хисен «еш» һәм «бик еш» кичерә.
- **57 проценты** гына мәктәпкә кызыксынып йөри.
- **10 проценты** бер тапкыр булса да буллинг белән очрашкан.
- **50 проценттан** да күбрәге даими рәвештә спорт белән шөгыльләнми.

(Тимченко фонды тикшерүе)

Илдар Мөхәммәтҗанов

«ВТ» белешмәсе

Буыннар теориясе нигезендә, «Z» буынына – 1997–2010 елларда, «Альфа» буынына 2010 елдан башлап (чикләр тәгаен түгел. – **Ред.**) туганнар керә.

Сораштыру

Дөнья бетүме, әллә камилләшүме?

**Гүзәл ИДРИСОВА,
Татарстанның атказанган артисты:**

– Барысын да заманага гына сылтап калдырырга ярамый, минемчә. Дөрес, дөнья бик нык үзгәрде. Бүгенге белем бирү системасы үзе үк кулга телефон алырга этәрә. Мәсәлән, хәзер кәгазь көндәлекләр юк. Өч улымның да ул көндәлекләре буш. «Ник тутырмадыгыз?» – дигәч, җавап итеп: «Укытучылар өй эшен электрон көндәлеккә яза», – диләр. Әмма анда кирәкле мәгълүмат гел булмый. Әле соңгы арада системаны үзгәрткәч, электрон көндәлеккә керә алмыйча тилмергән чаклар да була. Рәхәтләнеп кәгазь көндәлеккә язып кайтсалар, эше бетеп торыр иде югыйсә. Укытучыларны да гаепләп булмый. Аларның эше баштан ашкан. Төрле проектлар эшләргә дә интернет кирәк бүген. Без элек кулдан реферат яза идек. Хәзер исә электрон тактада презентация гына күрсәтәләр. Беренчедән, болар барысы да баланы телефонга чумдырса, икенчедән, алар ялкаулыкка өйрәнә. Реферат язып утырганчы, аны принтердан гына чыгару җайлырак бит. Тәрбия турында да онытырга ярамый. Бу яктан без – таләпчән әти-әни. Шул ук телефонда күп утырырга рөхсәт итмибез. Уку өчен кирәк булмаса, аны, башны ял иттерү өчен, ун-унбиш минут кына карый алалар. Буш вакытлары булса, урамга чыгарып җибәрергә тырышам. Үз йортыбыз белән яшәгәч җайлы, саф һавада берәр сәгать хоккей уйнарга мөмкиннәр. Ишегалдында һәркайсының үз көрәге бар. Менә шушы җирне сез көрисез дип, эш кушабыз. Өчәү бергә җыештырып куялар. Берәр җирдә чыгыш ясыйсы булса, кичтән киемнәрен, уен коралларын да үзләре әзерли. Гомумән, балалар белән даими шөгыльләнергә кирәк. Бу аларның физик сәламәтлегенә дә, сәләтләрен ачарга ярдәм итүгә дә кагыла.

Марат ГАРИФУЛЛИН, психолог:

– Ә нәрсәсе рәхәт соң бу тормышның? Замана балалары телефон, смартфон, гаджетларга бик нык бәйле. Кулыннан телефонын тартып алуга ук, үзләрен көчсез, моңсу хис итә башлыйлар, борчу, хәтта депрессиягә бирeләләр. Бу чор балалары хис-тойгылары ягыннан бик тотрыксыз. Алар үз кичерешләрен дә «смайлик»лар белән генә белдерә ала бит. Миңа мөрәҗәгать итүче әти-әниләр: «Яза белми, хәрефләре дөрес түгел», – дип зарлана. Аларны: «Киләчәктә гаджетлар буыны, гомумән дә, язу сәләтен онытырга мөмкин», – дип тынычландырам. Тик дөнья бетми, ә үзгәрә. Белгечләр раслаган: бүгенге балалар бер нәрсәгә игътибарны нибары сигез секунд кына юнәлтә ала. Ә мәктәптә дәрес кырык биш минут бара. Балаларга кыска мәгълүмат, вакыйгаларның мөмкин кадәр тиз алмашынуы кирәк. Дөнья тиз үзгәреп торгач, хәзерге буынга да гел белемен арттырып, камиллеккә омтылырга туры килә. Алар берьюлы берничә бурычны хәл итәргә туры килгән тормышта яши. Шуңа күрә өй эше әзерләгән арада кесә телефонындагы смс-хәбәрләргә бүленеп алулары эшкә берничек тә комачау итми.

**Минзилә ГАРИПОВА,
Балык Бистәсе районының
Олы Елга мәктәбендә
башлангыч сыйныфлар укытучысы:**

– Без алгарыш чорында яшибез. Ә нигә әле балалар артта калырга тиеш? Шуңа күрә замана балаларының холкы ниндидер гайре табигый дип әйтмәс идем. Еш кына: «Бүгенге балалар ялкау», – дигән кебек сүзләр ишетергә туры килә. Уйлый калсаң, ялкаулык элек тә булган. Хәзерге балалар арасында да төрлесе бар, әлбәттә. Авыл мәктәпләреннән чыгып шуны әйтәсем килә: балалар үзара аралашып, ярдәмләшеп яши. Бездә ял клублары оештырыла, төрле чаралар үткәрелә. Анда балалар бик теләп катнаша. Авылда телефонда утырырга да вакыт юк. Чөнки эш күп. Быел кар да шактый яуды әнә. Без тимурчылык эшләре оештырабыз, әби-бабайларга булышабыз. Балалар белән эшли белергә кирәк. Хәзер алар бик күп белә. Шуңа күрә заманасына күрә безгә дә җайлашырга туры килә.

ТАМАК ХАКЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Биектау районының Шыршиек авылында яшәүчеләр, чана өстерәп, күрше авылга кибеткә йөри. Кечкенә авылларның күбесенә автокибетләр килгәләвен беләбез. Әмма кышын юл булмаска да мөмкин. Беткән авыллардагы халык, карга күмелеп, ипи-сөткә тилмереп утырмыймы? «ВТ» хәбәрчесе ерактагыларның хәлләрен белеште.

Буа районының Өчмунча авылында 35ләп йорт бар. Заманасында гөрләп торган. Әмма яшьләр шәһәргә китеп, ә картлар бакыйлыкка күчеп барган. Менә шулай авыл халкы кимегән инде. Шулай да медпункт, клуб, мәчете бар. Көнгә биш мәртәбә азан тавышы ишетеп торалар. Кем өчендер рухи азык барыннан да мөһимрәк. Автокибет исә атнага бер мәртәбә килә.

– Кибет бар иде, аннары бетте. Ансыз яшәп була икән. Кеше теләсә нинди авырлыкка җайлаша бит ул. Кайсының балалары кайта, кайсы үзе күрше авылга барып ала, кайсы автокибетне көтә. Юк дип аптырап тормыйбыз. Балалар, атна саен кайтып, хәлне белешә, кирәк-ярагын алып кайта, – ди ялгыз яшәүче 68 яшьлек Земфира Кәлимуллина.

Шөкер, бураннарда юллар өзелмәгән. Килдураз авыл җирлеге урамнарны ачып торган. Баганада утлар яна, юл әйбәт. Шуңа күрә кибет булмау – монда кырык беренче хәсрәт.

Балык Бистәсе районының Кызыл Йолдыз авылында кибет беткәнгә – биш ел. Моннан өч ел элек районда «Сатучысыз кибет» проекты тормышка ашырыла башлаган иде. 40лап йорты булган әлеге авылда да ачканнар иде аны.

– Бездә бер елга якын гына эшләде ул. Башта халык йөрде. Бик уңайлы, җиләк-җимештән кала бөтен әйбер дә бар иде. Әбиләр яшьләргә ияреп бара, йә үзебез алып кайта идек. Бервакыт туңдырма ашыйсы килгәч, хәтта төнлә барып алдым. Кибет булмагач, хәзер алай йөреп булмый, – ди Лариса Кибякова.

Кибетсез яшәргә ияләшкән инде алар да. Күбесе кирәк-яракка күрше Котлы Бөкәш авылына бара. Анда бәяләр дә арзанрак икән. Атнага ике мәртәбә автокибет килеп киткәли.

Сан

«Татпотребсоюз» оешмасы мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта республикада **135** автокибет **1200** авылга хезмәт күрсәтә. Һәрберсендә айлык уртача товар әйләнеше – **376** мең сум. Моны бигрәк тә Чүпрәле, Кукмара, Чирмешән, Актаныш, Апас, Ютазы районнарында нәтиҗәле кулланалар. Соңгы елларда республикада **136** кибет файдалануга тапшырылган. Тагын **9** авылда төзергә җыеналар.

Фикер

Илдус ХАТЫЙПОВ, икътисадчы:
– Кечкенә авылда кибетне андагы халык түгел, кунакка кайтучы сорый. Кибет кирәк, авыл бетә, болай яшәп булмый, дип чаң суга башлыйлар. «Татпотребсоюз» оешмасында эшләгәндә дә, авылларда йөргәндә дә гел бу теманы анализлый идем. Авылда кибет тотудан файда юк. Беренчедән, анда төрле товар кайтарып булмый. Халык исә төрлелекне ярата. Әйтик, кибеткә бүген прәннек кайтты, ди. Аны сатып бетермичә, яңасы кайтмый. Озак ятса, икенче юлы сатучы аңа азрак заказ бирә. Без үскәндә, киштәдә эшләпә кәнфит, консервы, каен суы була иде. Бүген халыкны аның белән генә тотып булмый. Яшелчәсе дә, җиләк-җимеше дә кирәк. Ул гына түгел, сөте, мае, каймагы… Элек авылга сөт кайтмый иде бит. Кибет юк дип зарланганчы, шул ягын аңларга кирәк. Иң мөһиме – Татарстанның барлык авылына да ипи кайта. Барысы да запас белән ала. Элеккеге замандагы кебек кар базы түгел, суыткыч, туңдыргыч бар.

Лариса Кибякова әйтүенчә, яңа кибет ачудан мәгънә юк. Үзенең эшләп караганы булгач, барысын да яхшы белә. «Атнага бер мәртәбә товарга йөри идем. Аны 20 мең сумнан да кимрәккә алып кайту безгә отышлы түгел. Авыл кешесе искене ашамый. Аңа гел яңа алып кайтканы кирәк. Кибеткә бөтенләй йөрмәүчеләр дә бар. Ипине үзләре сала, балалары вак-төяген китереп тора», – ди ул.

Биектаудагы ун йортлы Шыршиекта хәлләр башкачарак. Кышын авыл тормышы – бертуганнар Илсөя һәм Гөлсинә апалар кулында. Илсөя Бикбаева авылга 5–6 ел элек ире Җәмил белән күченеп кайткан. Кибете, мәктәбе – бернәрсәсе булмаган авылга. Төпчек кызның әти-әни нигезен бетерәсе килмәгән. Карап тормасаң, җимерелә.

Кибет беткәнгә утыз еллап икән инде. Авылда азыкны үзең эзләп табасы. Әле ярый чанага бар да сыя. Шуңа күрә ике туган, чаңгы киеп, чана өстерәп, 4 чакрым ераклыктагы Дөбьяз кибетенә йөри. Кыз чаклары түгел. Илсөя апага апрельдә 75 яшь тула.

– Каймак белән коймак ашыйсы килә. Кибет булмагач, тыелып торасың. Теләгән бүләкне дә алып булмый. Йә өйдә запас тотасың, йә акчалата гына бирәсең. Казанга барып, кирәкләсен алып кайтабыз, – ди ул. – Ипи, сөт беткәч, өч мәртәбә күрше авылга барабыз. Юл йөрү газапка тиң. Басу уртасында ферма ясап куйдылар. Кайчак шуңа кадәр юлны ачалар, калганы чаңгы белән инде. Җәен авылга сөт, каймак, эремчек сатучылар килә. Әмма кышын бер техника да керә алмый.

Искермәсен өчен, ипине дә, сөтне дә туңдыргычка куялар. Ипине парда җылытып ашыйлар. Кайчак Илсөя апа үзе дә пешергәли. Әле 15–20ләп шешә сөтне карга тыгып куйганнар. Сөт күп кирәк.

Фираяныкы кирәк!

Җитмешкә җиткәндә дә 26 сыер асрап була икән ул! Арча районының Үрнәк авылында яшәүче Галәвиевләр әлеге шөгыльне ташларга җыенмый. «Бу – безнең яшәү рәвеше», – ди алар. Кызык, барысына да ничек җитешәләр?

«Бар әле, күр әле шул Фираяны». Арчага барган саен аның белән күрешергә тәкъдим итүчеләр очрап тора. Җай чыкмый: йә ул сату белән чыгып киткән була, йә безнең юллар кисешми. Бу юлы аны белүче танышым да: «Абзарларында тәртип, бар җире ял иткән. Пөхтә булгач, атна саен сөтен, каймагын алып торабыз», – диде. Күрше Балтачта да беләләр аны.

Без килгәндә, Фирая апа кухняда кайнаша иде. Яшь килен кебек анда чаба, монда чаба. Сатарга сөте калмаган, ә әрҗәдәге катык, каймак, корт үз иясен көтә. Арча халкы йә үзе килеп ала, йә хуҗабикә үзе җибәрә. Фирая апа аптырап тормый: шимбә – ял көннәрендә Балтачка ярминкәгә китә. Казанга чыгып китүнең дә бер кыенлыгын күрми. Авыл сыен көтеп торучылар булганда, нигә әле бармаска? Эшләп һәм йөреп торсаң, табышы да бар. Һәрхәлдә, шулай диләр.

– Хәзер авылда сыер асраучылар кимеде. Табышы юк, диләр. Ә сез ничек бизмәдегез? Малны караптәрбияләргә көч күп кирәктер? – дип кызыксындык.

– Сыер асраучылар картая, ялгыз кала, көтү көтәргә кешеләре калмыйдыр… Шөкер, без парлы бит әле. Икмәген, печәнен сатып алабыз. Эшчебез бар. Балаларыбыз булышып тора, – ди 69 яшьлек Фирая апа. Рәис абый исә сәбәпне ялкаулыктан күрә. Иренмәскә кирәк, бары шул гына.

– Сыерны берне түгел, күпләп асрарга кирәк. Шулай булганда кереме дә булачак. Сөтне хөкүмәткә тапшырудан файда юк. Үзең эшкәртеп, төрле ризык итеп әзерләп сату файдалы, – ди алар.

Галәвиевләр иртәнге сәгать 5тә үк аяк өстендә инде. Бергәләшеп чәй эчәләр дә, бисмилла әйтеп, эшкә тотыналар. Кичке сәгать унга кадәр тик тормыйлар.

– Бернинди авырлыгы да юк. Туйдырмый! Тәртипкә салынган, эше көйләнгән бит инде аның. Катык, каймак, май, йогырт, корт, сыр – барысын да ясыйбыз, – ди хуҗабикә. – Сыерларны савып, сөтне өйгә алып керәм. Сепарат аертып, каймак ясыйм. Катыкка диган сөтне утыртам, ул өч сәгать кайный. Эремчек салам, аннан кортын утыртам. Кайнап чыккач, иттарткычтан чыгарам. Бер дә аптырыйсы юк: барысы да үз җае белән бара.

Фирая апа аптырамаска куша, әмма 20 елдан артык шушы тизлектә тормыш алып баручы гаиләгә ничек гаҗәпләнмисең?! Хәрәкәттә – бәрәкәт, дип әйтүләре юкка түгел.

Ишек төбендә күп итеп буш әрҗәләр өелгән. «Ярминкәләргә шуларны тутырып чыгам», – дип ишарәләде Фирая апа. Заманында кибетче булып эшләгән икән. Сату итү шуннан бирле канына сеңеп калган. Шуңа күрә йөрүдән туктамый. Рәис абый – элеккеге механизатор. Берара кибеттә дә сату итеп алган.

Сөтнең литры – 50 сум. 350 граммлы каймак – 150, эремчекнең бер килосы – 180, катыкның литры – 120, кортның килосы – 350, сыр – 500 сум.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

АЯКСЫЗ КАЛГАН ИЛДУС АБЫЙ:

«БАШНЫ ИЯРГӘ ЯРАМЫЙ»

Чирмешән районының Әмир авылында гомер итүче 64 яшьлек Илдус Җиһаншинны күпләргә үрнәк итеп куярлык.

Йөгереп йөргән җиреннән аякларын кисәләр аның. Кыен чакларында янәшәсендә хатыны Нурсинә, өч баласы була. Әнә шуларның җылысын тойганга, төшенкелеккә бирелми дә. Үзе дә борын салындырып утыра торганнардан түгел.

– Безнең әти дә – сугышта аягын калдырып кайткан кеше. Әнием белән 7 балага гомер биргәннәр. Аяксыз дип тормадылар, әтине хисапчы итеп куйдылар. Районда кайсы колхоз артта бара, әти шунда эшләде. Аңа ияреп шактый йөрелде. Тик әтинең гомере кыска булды. 44 яшендә тромбы өзелеп вафат булды. Ул үлгәндә, иң олыбызга – 21, кечебезгә 4 яшь иде, – дип искә ала Илдус абый. – Әнием һәдиягә бик авыр булгандыр инде. Ул бер дә зарланмады. Тырышты-тырмашты, безне кешедән ким итмәде. Без бернәрсәгә дә мохтаҗлык кичермәдек. Әни дә 67 яшендә арабыздан китеп барды. Йөрәк, диделәр. Әни йөрәгендә ниләр булганын беребез дә белмәдек бит.

Инде иң олы абыйлары да исән түгел. Моннан 10 ел элек ул да йөрәк авыруыннан үлеп киткән.

– Авыр чакларымда янымда гаиләмнән кала туганнарым иде. Мин аларга бик рәхмәтле. 2011 елда аяксыз калдым мин. Гангрена башланды. Табиблар алдан ук авыруымның башкаларныкы кебек түгеллеген әйтеп куйды. Минем очракта аякларны кисеп кенә котылып була иде. Шулай да табиблар иң элек бармакларга операция ясады. Әмма чир чигенмәде. Шуннан соң сул аягымны боттан ук кисәргә кирәклеген әйттеләр. Каршы килеп кая барасың? Яшисе килә бит. Риза булдым, – ди ул. – Икенче аягым да тиздән киселде инде. Аякларымны югалтсам да, күңел көрлеген саклап калдым. Иң зур терәгем Нурсинә булды. Мин гомер буе шофер булып эшләгәч, балаларны да ул тәрбияләде бит. Хәзер шул балаларыма карыйм да сокланам. Хатыным ничек дөрес итеп үстергән аларны. Тәрбиянең күп өлеше анадан тора бит!

Олы кызлары Илсөяр, икенчесе Гөлгенә исемле. Улларына Илсур дип исем кушканнар. Сигез онык сөя бүген Җиһаншиннар. Гөлгенәләре ире белән күршеләрендәге йортны сатып алганнар. Әти-әниләренә терәк булып яшәп яталар. Илсөяр белән Илдус гаиләсе Чирмешәндә тора.

– Оныклар белән мәш килгән чак. Әле менә оныкларны районга алып барырга дип көтеп утырам. Протезга ияләнә алмадым, колясқада йөрим. Машинамны да кул белән йөртә торганга көйләдек. Урамга кадәр хатыным озата чыга да коляскаңы алып кереп китә. Мин кайчак аякларым юклыгын сизмим дә, – ди Илдус абый. – Тик кенә утыра белмим мин. Җәен балыкка йөрим. Коляска белән барып була торган җирләрне беләм. Әле тоткан балыкларым җәй аена кадәр җитәрлек.

Илдус абый белән Нурсинә апа турында сөйләшәбез. Күңеле тулып китә. Елыйм инде хәзер, ди ул. Әмма бераз тынычлангач, дәвам итә. Нурсинәм мине миннән дә катырак ярата, ди:

– Безнең заманда акчасына карап кияүгә чыкмадылар ул. Яратышып өйләнешкән буын без. Нурсинә миннән ике яшькә кечерәк. Югары Кәминкә авылыннан. Без аның белән 1981 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 17 минут 48 секундта язылышкан кешеләр. Мин бу саннарны гомер буе күңелемдә саклап тотам. Нурсинәле булуым белән бәхетлемен. Минем өчен генә туган кеше дип саныйм мин аны. Башка берәү булса, ташлап китәр иде. Казан хастаханәсендә ятканда, минем кебек аякларын кистергән ир-атлар күп иде. Шунда, син миңа гарип килеш кирәкмисең, дип килеп әйткән хатыннар да булды. Ә минеке гел янәшәдә иде. Шөкер, 40 ел бергә.

Нурсинә апа хат ташучы булып эшли икән. Илдус абый аны күрше авылларга йөртә.

– Сәламәтлегемне югалтсам да, мин – бик бәхетле кеше. Ир-ат, әти хөрмәтенә күмелеп яшим. Балалар да ишектән килеп керүгә иң элек минем белән исәнләшәләр, аннан гына әниләре янына китәләр. Менә шул да күңелгә рәхәт. Оныкларга кадәр янымда бөтерелеп, яратам, бабай, дип йөри. Балалар белән бездә атнага ике көн очрашабыз. Чәршәмбе һәм шимбә көннәрендә бергә җыелабыз. Менә шуннан рәхәте юк инде, – ди Илдус абый. – Бу дөньяда кешеләргә ярдәм итеп, булдыра алганны эшләп, туганнар белән дус-тату яшәргә кирәк. Беркайчан да башны түбән ияргә ярамый. Башыңны исән, бетте инде. Әнә шуңа да тормышка шөкер итеп, һәр көнгә сөенеп, кадерле кешеләреңне кадерләп, рәхмәтле булып яшәргә кирәк!

«УЛЫМ БАР БИТ МИНЕМ!»

Берсенә – 57, икенчесенә – 12 яшь. Алар сигез ел буе шатлык-кайгыларны бергә бүлешеп яши. Башкача мөмкин түгел. Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылында яшәүче Рәис Бариев улы Исламны бер ялгызы үстерә.

Язмыш шулай хәл иткән. Соңлап кына гаилә корган ир хатыны Зөһрә белән алты ел яшәп кала.

– Мин Зөһрә белән 2009 елда таныштым. Ул вакытта аңа 30 яшь иде. Матур гына яши башладык. Тормышта төрлесе булды, әмма минем аларны искә аласым килми. Иң аянычы – хатыным 4 яшьлек улым белән мине ташлап чыгып китте. Күп тә үтмәде, фаҗигале төстә вафат булды. Ул чакта Ислам кечкенә булса да, әнисез калганын аңлады. Миңа да рәхәт булмады. Ярый, янәшәмдә ярдәм итәргә әни бар иде. Кызганыч, бер елдан ул да үлеп китте, – дип сөйли Рәис.

Башта әнисе, аннан апалары, сеңелләре ташламый аны. Баланы аякка бастырыр өчен барысы да тырыша. Исламның да моңайган чаклары күп була, Рәиснең дә күңеле төшә. Әмма уртак телне таба алар. Икәү бергә бар каршылыкларны җиңеп яшиләр.

– Зөһрәнең миңа кияүгә килгәндә олы малае булган икән. Ул аны әйтмәде. Әнисенә калдырып киткән булган. Инде ул бала буй җиткән, армиядә, диделәр. Аның безгә килгәне юк. Кем белә, бәлки энесен эзләп табар, – ди Рәис. – Зөһрәнең әнисенең язмышы да аяныч: аны картлар йортына урнаштырганнар.



Рәис улын мактап кына тора. Спорт белән дус икән. Волейбол, баскетбол, футбол, хоккейга яратып йөри, ди. Бер генә буш вакыты да юк икән. 6 нчы сыйныфта укый. Шулай да кул арасына керә башлаган инде. Әтисе әнә шуңа сөенә.

– Зур маллар тотмыйбыз. Кәҗәбез бар. Тавыклар карауны эшкә санамыйм инде мин. Өйдәге эшләрнең яртысын «автомат» эшли. Керне юдыртып алабыз. Ашарга әзерләүнең бер авырлыгы да юк. Кичтән пешереп китә идем. Шөкер, быел бу эшемне улым алды. Мәктәптән соң, түгәрәкләргә барып кайта да, мин кайтуга, ашарга әзерләп куя, – ди Рәис. – Адәм баласын тормыш өйрәтә икән ул. Күңелсезләнеп утырган юк. Әни назы бирә алмаганыма гына борчылам. Мин көнозын эштә, кич кенә күрешәбез. Балам да иркәләнеп үсә алмый. Кечкенә булса да, тормыш итәргә өйрәнеп үсә.

Рәис, әллә өйләнимме, дип тә уйлаган. Өйдә хатын-кыз булса, бөтенләй башка бит инде. Тик улы әтисен бу уйдан туктаткан. «Икебезгә генә дә рәхәт бит әле», – дигән Ислам. Рәис улының сүзләре белән килешкән. Чит кешенең баланы үзенеке итеп ярата алмасын аңлый ул.

– Кешедән ким яшәмәскә тырышабыз. Улымның чын ир-ат булып үсүен телим. Тормыш мәшәкатьләре булмый тормый, хәмергә ябышмаска кирәк. Әгәр аның белән дуслашсаң, беттең инде. Әнә шуңа да, бирешмәскә кирәк, – ди ул. – Күтәрә алмаслык сынаулар булмый. Тормышта сабырлык та кирәк, тырышлык та. Әгәр көтеп ятсаң, китереп бирмиләр. Әле, шөкер, эшем бар. Тормышымнан зарланмыйм. Улым үсеп килә. Моңа кадәр тәртип бозмады, инде алга таба да сөендереп торсын иде. Ә миңа аның бәхетле булуын күреп, улым өчен шатланып, оныклар сөеп яшәргә язсын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЗӨФӘР ХӘЙРЕТДИНОВ:

«ҖЫР ИҖАТ ИТҮНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕ ТӨШТЕ»

Аның белән төрле темаларга сөйләшеп була. Авторлык хокукларын яклау буенча да зур белгеч ул. Җырчы буларак та әйтер сүзе бар. Композитор буларак та фикерләре үтемле. Җыр сәнгатенең асылы нәрсәдә? Яхшы җыр кайчан туа? Талантны нәрсә харап итә? Бүген без шул сорауларга җавап эзләдек. Әңгәмәнең сәбәбе дә бар: Татарстанның халык артисты Зөфәр ХӘЙРЕТДИНОВ иҗатының 40 еллыгын сәхнәдә билгеләп үтәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Зөфәр абый, 40 ел – аз вакыт түгел. Иҗат турында сүз барганда бигрәк тә. Артка карап, нәтиҗә ясасак, сез иҗатыгыздан канәгатьме?

– Бөтенләй канәгать булып булмый инде ул. Ә икенче яктан, мин бит музыка өлкәсенә җырчы булам дип килгән идем. Тормыш шундый итеп борып куйды: хобби буларак башланган эшем җырчылыкны икенче планга калдырды. Хәзер тамашачылар җырчы Зөфәр Хәйретдиновка караганда композитор Зөфәр Хәйретдиновны күбрәк белә. Бу җәһәттән җырчылыгымның көнчелеге дә килә. Аннары, ярар инде, дип куям. Бу ике һөнәр бер-берсен тулыландыра гына бит. Ә композиторлык эшчәнлегемә быел – нәкъ 40 ел. Мин шунысына горурланам: җырлар язылып кына калмады, шул җырлар, дөньяга чыгып, татар халкы арасында популярлык казанды. Бу – бик зур бүләк, бик зур куаныч. Җырлау теләге кимегән булса да, җыр язу теләге һаман күңелдә яши. Ул юктан гына барлыкка килгән һөнәр булмаган икән. Кирәкле һөнәр булган. Элегрәк мин: «Дөньяда яраткан өч нәрсәнең берсе – җырлау», – дип әйтә идем. Алар дүртәү икән. Дүртенчесе – көй язу. Бу – яшәешемнең мәгънәсе дә.

:: Композитор буларак, сезне таныткан төп 3 җырны әйтегез әле.

– Бигрәк аз булды бу... Шуңа җавап бирү дә читен. Берсен әйтсәң, калганнары үпкәләп калыр кебек. Аннан килеп, миңа ошаганы башка кешегә ошап бетмәскә дә мөмкин. Кайчак язасың һәм һич кенә дә бу җыр танылыр дип уйламыйсың. Ә ул киресен раслый. Миңа ошаган иң популяр җырларның берсе – «Кайда син, гармун?» Халык «Су буенда учак яна», «Салкын чәй», «Пар алма» кебек җырларны әйтергә мөмкин.

:: Ә Алсу Хисамиеваны күтәргән җыр?

– «Миләшләрем»не дә халык ярата. Әйтәм бит, бу сорауга җавап бирү читен. Уйлап баксаң, иҗат кешесенең бер генә визит карточкасы була кебек. Менә мин иҗатымны шушы җыр ачты дип конкрет бер җырны гына әйтә алмыйм. Җырчыларның барысы белән дә диярлек эшләдем. Җырларым алар репертуарындагы гади җыр гына түгел, визит карточкаларына әйләнде. Әйтик, Зөһрә Шәрифуллинаның «Су буенда учак яна» җыры. Салават «Салкын чәй»не 2000 елдан бирле җырлый, һаман да репертуарыннан төшми. Саный китсәң, күп инде.

Җыр иҗат итүнең дәрәҗәсе төште. Җырчылар үзләре җыр язарга алынды. Көнчыгышка яки Европага охшатып язучылар да барлыкка килде. Бер караганда, бу начар түгел, җыр сәнгатен баета гына кебек. Әмма барыбер асылыбыздан читкә китәргә ярамый.

Аннан тагын шунысы сөендерә: үз юлын таба алмаган җырчылар ретро җырларга мөрәҗәгать итә башлады. Бер караганда, дөрес бу. Ни әйтсәгез дә, ул вакыттагы җырлар бүгенгесе белән чагыштырганда мәгънә ягыннан саллырак. Бүген эчтәлек бик аксый. Тагын җырны аңлап җырлау да бар бит әле. Бүген аңлап җырлаучылар бик сирәк. Бу кимчелек хәтта популяр булып киткән җырчыларда да бар. Алар бу хәлдән тавышның, музыканың матурлыгы, сүзләрнең үтемлелеге белән чыга. Кайбер җырчыларга әйткәлим дә. Кабул итүчесе дә, үпкәләүчесе дә бар.

:: Әдәби премияләр тапшыру тантанасында Ркаил Зәйдулла язучыларга: «...язар өчен укырга да укырга әле безгә. Тапталган эздән барабыз», – дигән сүзләр әйтте. Әдәбиятта хәлләр шундый, ә җыр сәнгатендә ничек?

– Башта сүз, ягъни шигырь туа. Тик хәзер сүзнең асылына, шигырьнең сыйфатына игътибар кимеде. Мине, мәсәлән, музыка язарга бары тик яхшы шигырь генә илһамландыра ала. Башта музыка язып, аннары аңа шигырь эзләп йөгереп йөргәнем булмады. Бүген, чыннан да, каяндырниндидер көй алалар да шуңа сүз яздыралар. Әлбәттә, мондый җырдан мәгънә эзләргә кирәкми. Мәгънә артында бик зур хезмәт, эзләнү, бик күп уку ята да инде. Үзем дә 5–6 нчы сыйныфларда укыганда шигырьләр яза идем. «Яшь ленинчы» газетасына да җибәрдем. Шуннан бер көнне мәрхүм Роберт абый Миңнуллиннан җавап килеп төште. «Энекәш, шигырьләреңнең эчтәлеге бар, әмма рифма аксый...» – дип, кимчелекләрне әйткән дә, боларны төзәтү өчен укырга кирәк, дип киңәш биргән иде. Шуннан укый башладым. Тора-бара уку минем өчен чиргә әйләнде. Авыл китапханәсендәге бөтен китапны укып бетердем. Аңа карап, шагыйрь булып китмәдем, әмма шигъриятне яхшы аңлыйм. Бу композитор эшчәнлегемдә бик зур ярдәм булды. Камил шигырьдән, чын поэзия үрнәгеннән генә яхшы җыр туа.

:: РАОда хәлләр ничек?

– Быел мартта аннан эштән киткәнемә ике ел була. Үзем композитор һәм җырчы да булгач, ул эш миңа бик җиңел булмады. Бу бит – авторлык хокукларын яклый торган оешма. Җыр иҗат иткән авторларның хокукларын кем сакламый? Җырчылар. Алар документ белән тиешле гонорарны күчерергә атлыгып тормый. Шуңа күрә мин 20 елдан артык ике ут арасында яшәдем.

:: Авторлык хокукларын яклау буенча соңгы елларда алга китеш бармы?

– Үзгәреш булсын өчен, бу өлкәгә кагылышлы законнарны тагын да катгыйрак итеп эшләргә кирәк, дип уйлыйм.

> Ул законны бүген кем эшләтә? Россия авторлык хокукларын яклау оешмасы. Бу – иҗтимагый оешма. Аның вәкаләте дә бар, тик мөмкинлекләре җитәрлек түгел. Ә чит илдә авторның хокукын бозып кара син, миллионнар белән исәпләнгән штраф түләячәксең. Ә бездә минималь штраф күләме – 10 мең сум.

Бу гына авторлык хокукын бозуга киртә була алмый инде. Һич югы бер бозсаң – 10 мең, икенчесендә 20 мең сум дип арттыра барсаң, ниндидер үзгәреш булыр иде.

:: Иҗат кешесенә иҗади берлекләр ни дәрәҗәдә әһәмиятле?

– Мин аларны совет заманыннан калган бер традиция дип кабул итәм. Аларның бүген кирәге шулкадәр генә. Композиторлар берлегенә консерваториянең композиция бүлеген тәмамлаган һәм күләмле әсәрең булган очракта гына кабул итәргә мөмкиннәр. Әгәр җыр иҗат итү белән генә шөгыльләнсәң, профессиональ белемең булган очракта да, берлеккә керә алмыйсың. Язучылар берлегендә андый чикләү юк кебек. Иҗатың булса, дипломың булу мәҗбүри түгел. Язуың әллә ни салпы булмаса да, алалар бугай. Һәрхәлдә, мин Берлек әгъзасы булган бизнесменнарны, шагыйрь исемен күтәреп йөргән кешеләрне беләм. Язганнарын үзләреннән башка укучы да юк бит инде. Шул ук вакытта шундый шәп шагыйрьләр бар, әмма алар Берлек әгъзасы түгел. Иҗатка анда әгъза булу-булмау берничек тә тәэсир итми. Бигрәк тә композиторларга. Сара Садыйкова язмышын гына искә төшерик. Иң популяр композитор иде, ә Берлеккә кабул итмәделәр.

:: Ә композиторлар бер-берсе, яңа әсәрләр белән кайда таныша ала?

– Советлар чорында Берлекләр нәкъ менә шушы һәм башка функцияләрне үтәр өчен оештырылган да инде. Хәзер бу функция бетте, Берлеге калды. Мин хәзер Композиторлар берлеге турында әйтәм. Анда яңа әсәрләр яңгыраган, тәүге бәя бирелгән. Кыскасы, иҗат процессы барган. Бүген мин бу оешманың нәрсә белән шөгыльләнүен белмим. Әле бит безнең Үзешчән композиторлар берлеге дә бар. Аның җитәкчесе – Риф Гатауллин. Үзешчәннән күтәрелеп, җырлар яза башлагач, консерваториянең композиция бүлегендә укыды. Ул Композиторлар берлегендә дә бар, үзешчәннәр өчен дә оештырды.

Блиц-сораштыру

:: Җыр белән үз ярыңны табып буламы?
– Ришат Төхвәтуллин башкаруында «Шомырт бәйләме» җырын әйтәсеңдер. Ул сәхнәдән: «Зөфәр абый, шушы җырны җырлап, ярын тапкан, бәлки, мин дә табармын әле», – дип сөйли иде. Билгеле, бу фантазия иде. Ә җырның тарихы болайрак. Җырның авторы – Илсур Хөснетдинов. Миңа аның шигырендә «шомырт бәйләме» дигән тезмә ошады. Үземнең авыл күз алдына килде. Безнең авылда инеш буенда гел шомыртлар үсә. Ну шигырь пешеп җитмәгән иде. Мәрхүм Илсур абый – профессионал түгел бит инде, совхоз директоры. Шуңа фикер бар, поэзия юк. Үзгәртсәм, ачуланмыйсыңмы, дигәч, каршы килмәде. Язып бетергәч, үзенә күрсәткән идем, нәкъ минемчә булган, диде. Җыр менә шулай туды.

:: Укучыга нинди 3 китап тәкъдим итәр идегез?
– Һәр татарга өстәл китабы итеп Мөхәммәт Мәһдиев томлыкларын тәкъдим итәм. Шагыйрьләрдән – Мөдәррис Әгъләм. Драматургиядән – Туфан Миңнуллин. Туфан абыйның драматургиясе генә түгел, истәлекләре дә, трибунадан ясаган чыгышлары да кадерле. Дәүләт Советында аның кебек депутат башка булмады.

:: Нинди хоббигыз бар?
– Ул һаман шул ук: волейбол уйнау.

Кызганыч, бу Берлек кәгазьдә генә калды. Барлыгын белүче дә булмагач, аның да кирәклегендә шигем зур.

:: Сезгә алмаш бармы? Үзегезгә кемнәр үрнәк булды?
– Минем өчен гомер-гомергә Илгиз Закиров белән Фирзәр Мортазин үрнәк булды. Фирзәрнең җырларын башкарганым булмады, ә Илгиз абыйның җырлары белән иҗатым башланып китте. Әйтик, ул – «Моңлану» дигән җырның көй авторы. Профессионаллардан Луиза Батыркаева белән Резедә Әхиярова җырларын башкардым һәм үземә өлге дип кабул иттем. Ә бүген иң ошаган композиторларның берсе – Оскар Усманов. Башта мин: «Татарча да белмәгән егет ничек инде татар җырларын яза?» – дип гаҗәпләнә идем. Үзеннән дә сораганым булды. Баксаң, шагыйрьдән сүзгә-сүз тәрҗемә соратып ала икән. Аның җырларында бит сүз белән музыка шулкадәр тәңгәл. Сүз уңаеннан, күп җырларда бу ике дөнья аерым-аерым яши. Элек-электән Оскар җыр язуга зур фәнни бер эш итеп карый иде. Хәзер инде ул татар телен белә һәм күп кенә шагыйрьләрнең шигырьләрен төзәтә дә әле. Аның бер генә кимчелеге бар – артыгы белән тыйнак. Аның кадәр тыйнак кеше башка юк. 2000 нче еллар – Оскар Усманов еллары. Иң күп популяр җырларны ул иҗат итте. Бер елны «Татар җыры»нда 18 номинациянең 7сендә аның җырлары җиңү яулады. Шуңа күрә гел әйтәм: тыйнаклык – билгесезлеккә туры юл.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

(ХИКӘЯ)

АЙЗИРӘК ГӘРӘЕВА-АКЧУРА

КУЕНЫҢДА НИ БАР?

<Ахыры. Башы 29 гыйнвар, 2, 9, 16 февраль саннарында

Мөнир карт белән чәй эчкән агач өстәл янына килеп утырды, җеназаханә тәрәзәсендәге карлыгач оясы күзенә чалынды. Аста – җеназаханә тынлыгы, өстә – оя тулы тереклек, чырык-чырык иткән кошчыклар тавышы.

Шул ук вакытта картның соңгы сүзләре колагында яңгырагандай тоелды.

– Минем әнием аңлатыр иде, бабамнарның телсез кардәше калган. Чикләр ябылгач, хатлар бөтенләй киселгән. Телсез кардәшләренең хәлен белә алмый дөньядан кичтеләр. Бәлки, шул телсез кардәшләренең балалары, оныклары бардыр, чөнки аның кияүгә чыгуы турында хәбәрне алганнар. Бер Аллаһ белер, ничек яшәгән. Бабам куенында саклап китергән Коръән апасыныкы бит, юлга чыгар алдыннан ул биргән аны. Кайтсын ул мәмләкәткә, кайтсын…

Мөнир карт барысын хәтерли иде. Ә яңа мөһаҗирлек зиһеннәргә нинди эзләр салыр?! Балалары, җир читенә китүләренә карамастан, татарча сөйләшеп, дога кылып, бабаларын искә алырмы?! Яңа мөһаҗир куенында тормыш юлының иң кыен, хәтәр, көтелмәгән борылышларын кичкәндә, авырлыклардан йолып, упкыннарга очудан саклап кала алырлык, торыннарына кадәр барып җитәрлек бер көч бармы?! Илнур, Мөнир карт төсле, куенын капшап куйды. Куены буш дисә… Буш түгел. Авылга кайткач әбисеннән ишеткәннәр белән тулы: «Бабамның үги әнисе бик тәрбияле, бик мәрхәмәтле, әмма телсез булган, диләр. Минем аны үземнең күргәнем булмады, мин туганда үлгән иде инде. Бабам, беренче хатыны үлгәч, өч бәләкәй баласы белән тол калган. Күрше авылда телсез хатынның беркемсез, ялгыз яшәгәнен ишеткән. Кемдер, кызганган, ди, кемдер, электән атасын белгән, ди. Кыскасы, барган да алып кайткан. Зифа әби бабайның һәм аның ике туганын үз әнкәләреннән ким бакмаган, дип сөйләнәләр иде. Син, улым, тап ул картны, сөйләш. Бәлки Зифа шул Миңзифадыр…»

Теге вакытта, мосафир киткәнгә берничә атна узган иде, мәчет имамы җомга намазыннан соң сүз алды:

– Җәмәгать, таралышмый торыгыз әле. Ике белдерүем бар. Беренчесе күрше мәхәлләгә кагылышлы. Җәмигъләрен сүтмәкчеләр, мәхәллә халкы аптыраашта. Бер тиле коега бер таш атса, кырык акыллы чыгарта алмаган, диләр бит. Шуның кебек, берсе, мәчеткә терәтеп: «Минем җирем, ничек телим, шулай кулланам», – дип, өч катлы күңел ачу-сәүдә йортын салып куйды да, җәмигъ ихтыяҗларына кирәкле эшләр башкару кыенлашты. Шикаятьләр килә икән. Эш шунда ки, хәзер мәчетне сүтеп, мәхәлләдәге җиргә бәйле һәр мәсьәләне хәл итмәкчеләр. Белеп торыгыз, дип әйтүем, күрше мәхәллә халкы риза түгел, бик нык аптыраашта.

Намазга җыелганнар гөрләшеп алды. Адәм баласына һаман җир җитми! Менә галәмәт заманнар җитте! Җаһиллек! Имансызлык! Хәзрәт, кулын күтәреп, сөйләшүне туктатты, кабат сүз башлады:

– Тагын бер белдерүемне тыңлагыз. Намаз кылучылар арасында татарлар бардыр. Берегез Коръәнен онытып калдырган. Бактым, бик иске китап. Петербургта басылган. Эчендә иске төрекчә язулары бар. Кыйммәтле язулардыр, дип төшендем. – Имам кулындагы Китапны өскә күтәреп күрсәтте. – Без башта Коръән укырга өйрәнүчеләр китергәнме дигән идек. Сораштырдык. Юк икән. Коръән кемнеке, янына килсен. Хәзергә сүзем тәмам.

Мәчет ишек төбендә үк диярлек торган Салих, Коръәнне элегрәк күргәне булганга күрә, тиз танып алды. Чыгарга ашыккан халыкны ерып, арадашыннан бәрелә-сугыла, хәзрәткә таба ашыкты.

– Хуҗасы, Аллаһ рәхмәт әйләсен, абзыем була. Күптән түгел бакыйлыкка күчте. Олы кеше, аерылырга теләмичә, гел үзе белән йөртер иде. Куенына кыстырып, мәчеткә алып килер, шуннан укып аңлатыр иде.

– Әфәндем, җеназаханә тәрәзәсен ачтырмаган, ике тарафына язу ябыштырган, шулай итеп карлыгачларның оясын саклаган абзыйммы әлләә ул?!

– Әйе, әйе!

– Аллаһ рәхмәт әйләсен!

– Амин. Хәзрәт, китапны миңа бирсәгез, күз карасыдай саклармын. Балаларыма әманәт итәрмен.

Салих китапны сак кына куенына тыкты һәм мәчеттән чыгу ягына таба атлады.

Тәрәзә өстендәге йомры балчык оядан дөнья кочагына талпынган дүрт кошчыкның бер-бер артлы башлары күренде.

***

Аңлатма

Филҗан – төрек чәй стаканы.
Әүкате бар – барлыклы.
Кафәс – читлек.
Нәфәс – сулыш, кыска вакыт.
Кафилә – кәрван.
Бирмәгәйләр хисса һәргиз гафилә… – бирмәсләр өлеш һич тә гамьсезләргә.
Басмагыл юлыга рәһбәрсез кадәм… – юлга җитәкчесез, башлыксыз аяк басма.
Мизар – каберлек.
Хассияте – рәвеше.
Җаһиллек – наданлык.

Шигырь сүзләре – Мөхәммәдьяр, «ТӨХФӘИ МӘРДАН» («Егетләр бүләге»)нан.

Айрат СУФИЯНОВ

Яңа учак

Давыл сукты… гүя набат,
Күккә карап, соңгы кабат
Талпынды да сынды нарат.
Туфрак дымын сулап,
Белмим, нәрсә уйлап,
Ыңгырашты тамыр…
Өскә чыкса? Ничек
Булган кодрәтенең
Какшаганын таныр?..
Көпшәклекнең тәнен,
Кортлар, җиңел ертып,
Үзәккә юл тотып,
Татып аның тәмен,
Таралырлар артып,
Шул төбәкнең ямен,
Гамен аска тартып…
Давыл сукты… гүя набат,
Күккә карап, соңгы кабат
Талпынды да сынды нарат.
Кояш сүнде, баеп…
Хыял – колын – ал таң,
Тояклары таеп,
Өзгәләнде кинәт.
Ирененең бер як чите белән
Тән колагын тешләп
Йоклап китте һәм төшендә күрде:
Нарат исән иде…
Җил дә исә иде
Кояш чыккан яктан.
Әйтерсең лә тормыш
Яңа учак яккан!

Ат исе

Хәтердә – кыш…
Салкын…
Кайда яшьләр
Җырлап узган гармун уйнатып?
Ирек сулап, язга чыгармынмы,
Чабармынмы болын буйлатып?

Карда ауныйм… Арынасым килә,
Котыласым кара төкләрдән.
…Агарган да, сафланган да мәлдә
Ярдәм иңәр кебек күкләрдән.

Мин ат идем… Азмы йөк ташыдым,
Төшенә дә кермәс күпләрнең.
Ап-ак карны пычратканым өчен,
Юк, каргышы төшмәс күкләрнең…

Әллә төштеме соң? Ни сәбәпле
Хөрмәт бетте бүген атларга?
Камыт кискән җилкәм суерылган,
Аяк сызлый гаярь атларга.

Атны түгел, чорны чалганнарны
Нинди исем белән атыйсы?
…Ыңгыраша дала киңлегендә
Кылганнарга сеңгән ат исе…

Уем якты

Уем – сөңге… Кара төнне тишәм.
Кайда соң син көткән яктылык?
Гомрем буе дөрләп, чәчрәп яндым,
Кояш чыгышына тартылып.
Кара төннән көнгә чыксам икән,
Җанны тапламыйча ак булып.
Уем якты… Яхшылыкка юрыйм.
Баш очымда балкый ак болыт!

Сагындым

Гөлләр елмаюын сәбәп итеп,
Йөрәгемне ут-ялкында өтеп,
Сүзләр көчсез, шундый сагындым,
Самими моң белән карап торган,
Һәркемнән дә үзен яраттырган
Ихласлыгын сабый чагымның…



Гаффарларның олысы | ...-талу белмәс | Татар әкиятләре герое | ... Хисмәт | ...-кулаларның сызласын | Айга 4 чыга торган | Шалкан тартып чыгаручы | ...-йолт | ... өстендә эш | Катнаш нәмәрсә | Казан символы | Казанда ... уеннары | Кебаб төре | ТВ-канал | Пешерәсе бар | Тунудан дерелдәү | ... Расих | Балтач районы авылы | 12 ай | Зөлкарнәй | Пилмән эчендә | Юмор остасы Сабиров | ... белән кылыч | Пермь күршесе | Теләче районы авылы | Чыктым ... күпер | Тукмаклы спорт | «Чук һәм ...» | Сүрә | Әлиф, ..., та, са | Казанда ... заводы | ... халык | ...-әни | Польша каласы | Ит һәм яшелчә ризыгы | «Остров сокровищ» герое | ... Әхмәтҗанова | Татар җырчысы Ширин Әл-... | Бабай хатыны | Җеп | Мәрхүм ... Кыямов | «Ивеко» йөк машинасы төре | Тегермән порошогы | Дезодорант | Бию өлеше | Әрмән хәрефе | ... Герстер | Крутушка лагере | Г.Сафин җыры | Корьән ашында түрдә кунак | Пекин илбашы | Нота | Журналист Семён ... | Киев мэры | Британ автомобиле | Вә | Хак | Өзелам дип тора | Капка бикләү җиһазы | Акчалы челтәр | Исәр | Кыска Миләүшә | «... Фэмили» кибете | Массажист эш «өстәле» | Газап | Янгын | Диварлы кредит | Офис самавыры

Сканворд җаваплары

Горизонталь: ару, Әсхәт, хаталар, ялт, тычкан, Адана, гибрид, Арбаш, ел, ит, калтырану, калкан, Нырсы, Нәс, Оханск, әби, әти, бау, он, Стралис, Байтик, Фа, ча, Ирадә, Си, Пегов, Ягуар, Славутский, келә, Миля, НЛ, тән, Рич, иза, кулер, ипотека.

Вертикаль: Гек, Әлфис, зилант, Ләис, па, БРИКС, Тчев, рагу, Фәрхетдинова, Отмар, Ливси, Әхәт, чи, Данир, Кличко, аяк, Сания, ут, Атилла, Анси, тиле, атналык, бәя, нәзек, убыр, РТР, ба, Гөлнара, абыстай, дары, утрак, аша, ре, бокс, Агутин, илә.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Татарстанда аларның саны 15700 баш исәпләнә:
а) куян;
б) поши;
в) төлке.

2 «Шаталак» сүзе татарда нәрсәне аңлата?
а) пычрак;
б) куркыныч;
в) тиктормас.

3 Елда ничә атна?
а) 51;
б) 52;
в) 54.

4 Аркадий Гайдарның «Чук һәм Гек» әсәре 1939 елда беренче тапкыр нинди атама белән басылган?
а) «Телеграмма»;
б) «Телеграф»;
в) «Телевизор».

Җаваплар: 1.б); 2.в); 3.б); 4.а).

Әз-мәз мәзәк

***

Гаиләдә уртак фикергә килү болай була. Иренең тау чаңгысында шуасы килә, ә хатыны диңгез турында хыяллана. Ахыр чиктә диңгезгә баралар, әмма иренә үзе белән чаңгы алырга рөхсәт ителә.

***

Балалар бакчасында ишеткәннәрдән:
– Әти мине кибеттән сатып алган.
– Ә мине әтием ләкләктән соратып алган.
– Ә минем әти – бик гади кеше, бөтен нәрсәне үзе эшли.

***

– Сезнең песиегезнең кушаматы ничек?
– Көндезме, әллә иртәнге биштәме?

***

– Кияүгә чыгар алдыннан егетләрне дә карбыз сыман сайласаң иде ул: башына шакып карадың, тыңладың һәм алдың.

***

Кибеттә:
– Тәк. Миңа кызыл уылдык, иң кыйммәтле шоколад һәм каклаган каз бирегез.
– Ой, мине дә алыгыз әле.

***

Сезнең дә шулаймы? Шимбә көнем «ниһаять, яллар» дип уза, ә якшәмбе – «иртәгә эшкә» дип.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 11272 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 221

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.)**.
16+